

Нәҗибә Сафина



# *Без — шигырь, тормыш — проза*

Шигырьләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос = Тат) – 5
С 24

**Сафина Нәҗибә**

С 24 Без — шигырь, тормыш — проза: Шигырьләр.— Казан: Татар.кит.нәшр., 2004.— 207 бит.

Әлеге китапта шагыйрәнең соңгы елларда язылган лирик-фәлсәфи шигырьләре тупланды.

ISBN 5-298-01367-8

© Татарстан китап нәшрияты, 2004

## ВАКЫТ ЧИКЛӘРЕННӘН УЗАЧАК

Һәр шагыйрьнең үз тәкъдире, үз юлы, үз фәлсәфәсе, үз тормышы, үз аңы, үз дөньясы булган кебек бу шагыйрәбезнең дә үзенә генә хас, башкалардан үзгә сыйфатлары күп. Әмма аның иң төп үзенчәлеге, үзенә генә хас тоемы, үзенә генә хас шигъри шәкел тудыра белүе, совет заманынчарак әйтсәк, образлар коя белүе сокландырырлык.

Шагыйрәнең лирик каһарманы бу дөнья буйлап шулкадәр иркен, шулкадәр колачлы килә һәм күңел түренә кереп утыра ки, хәтта үзең дә тоймый каласың. Нәҗибә Сафина дип, танып, аны бүтән беркем белән дә бутамыйсың, үз итәсең.

Мин яхшымын дип түгел, сылулык турында һич сүз дә юк, мин менә шушындый, ягъни минем кебек какшамас — көчле-дәртле булсаң, иҗатымны да кабул итүеңә шигем юк, дигән сыман ул ыргылып, бер сулыштан аласы кирмәнен, аласы ныгытмасын ала белә. Бу инде Нәҗибәнең табигатьтән, Аллаһыдан килгән сәләте. Укысагыз, аның башкаларга һич кенә дә хас булмаган метафора, стандартка кермәгән шәкел-образларын күргәнсездер.

Аннары аның шигъри китаплары да гадәти китап түгел, шагыйрәнең бәгыреннән кайнап чыккан бер монолог. Үзе, туган җире, иле, милләте, җир, дөнья, галәм һәм дөнья күчәре, Кеше турында хикәят-роман булып яңгырый.

Бай һәм киң, тирән вә биек, бөек, иркен һәм ирекле татар теле!

Моң... моң... моң.

Шагыйрь гаҗәеп сәер холыкка ия — егет холыклы, үзенчәлекле иҗатчы һәм үз иҗатындагы каршылыкларын күрсә дә, аның табигатьтә бу шулай булырга тиешме, юкмы дигән шикләнүгә күңелдә урын да калдырмый.

Аның шигырьләренә генә хас нәфислек, балкыш, гөләп исләре генә килеп торган чәчәкләр белән бергә ачы әреме дә булган киң дала, кулаякларыңны каната торган биек кыяларда үсүче ак бордак чәчәге — эдельвейсның да матурлыгын күреп, әнҗе исен тоясың.

Татлылык белән әчкелтемлек кочаклашкан бу иҗатта. Борычның да уты бар аларда. Өстәвенә, ялкынлы да! Алар салкын карлар эчендә үсеп чыккан ак чәчәкләрдәй туңмый да, бозланмый да тирә-якка нур чәчеп, җирне ямьләндереп утыралар. Яктылык һәм җылылык нуры тарала бу шигырьләрдән. Уйландыра алар, гамьгә сала, үз-үзеңне капшап карыйсың, үз-үзеңне эзлисең. Нигә минем үземдә мондый кайнарлык юк! Нигә мин дә бу кадәрле итеп кешелек дөньясының бер генә кешесен булса да җылыта алмыйм?!

Еллар узар. Гомер көймәсе безне башка ярларга илтеп төшерер. Әмма мондый шигърият вакыт чигеннән ашып, киләчәк буыннарга хезмәт итәр, яшь буыннарны тетрәтер.

*Әхмәт Гадел*

# I

*Гәүһәрне таш дию белән ул – таш булмас,*
*Тикмә кеше гәүһәр кадерен белә алмас,*
*Бу нәзымның кадерен бары ахмак белмәс,*
*Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер имди.*

Кол Гали
(1183 — 1236)



## *Кеше — шигырь...*

*(Туган көндә гәпләшү)*

*Р.Т.–га*

Дөнья беләсезме нидән тора?
Күләсезме? Анысын беләсез.
Беләбез дип уйлап, көлә-көлә,
Әмма белә-белә бөләсез.

Дөнья юктан гына тора юкса:
Кояш чыгу, кояш батудан.
Бату белән чыгу арасында
Кочаклашып йоклап ятудан.
Менә шулай, Роза,
ә калганы проза.

Дөнья тора тагы юктан гына:
Яфрак белән яфрак арасы.
Яфрак өзелгәндә ярасына
Яңа бөре яралып каласы.

Дөнья тагы шунсыннан да тора:
Сөзелүдән тора, өзелүдән.
Тигезләргә диеп басканнарның
Аяк асларында изелүдән.

Тагы шуны белүдән дә тора:
Изелү түгел ул тигезләнү.
Тигезлимен диеп тилергәннең
Каршысында түгел ул тезләнү.
Менә шулай, Роза,
ә калганы проза.

Дөнья, беләсезме, нидән тора?
Баскан саен үзләнүдән тора.
Югалтуын аңлый алса кеше,
Берөзлексез эзләнүдән тора.

Эзләнүдән тора һәм табудан.
Табынучылардан һәм «табу»дан.
Куып җитәм, диеп, бу дөньяны,
Туктый алмый бермәл гел чабудан.

Әле тора туктап тын алудан,
Үткәннәрдән гыйбрәт алудан.
Үткән мизгелләрнең оч-очларын
Ялгый алмый гаҗиз калудан.
Менә шулай, Роза,
ә калганы проза.

Мизгелләрдән тора, ә мизгелләр
Үз ярларын табып җыелалар.
Кеше гомерендә мизгел булмас
Пүчтәкләре аның җуелалар.
Менә шулай, Роза,
ә калганы проза.

Ә менә бу мизгел җуелырмы?
Гомер ярларына җыелырмы?

Гомерләрнең калган яртысында
Яшен генә булып тоелырмы?
Сорау туа, Роза,
ә калганы проза.

Дөнья тора теләк теләүләрдән.
Теләкләрнең чынга ашуыннан.
Теләгәннәр инде юш килде, дип,
Күңелләрнең күккә ашуыннан.

Тагы әйтәм дөнья нидән тора:
Бер-береңә изге уй кылудан.
Айкалудан тора, чайкалудан.
Бар дөньясы хәер сорашканда
Рухың белән исән, бай калудан.
Кеше — шигырь, Роза,
ә яшәү — проза.

## *Аерылмасны каермагыз!*

Бу дөньяга ничек килгәнемне
Хәтерләмим мин дә.
Туган телдә тәүге бишек җырын
Мин ишеттем синдә,
Башкортстан — мәгърур Урал иле.
Бишек җырым минем
тәүге җырым –
Тукай теле иде.
Шул җыр белән җанга килеп керде
Бөек Тукай иле.
Татарстан — моңлы Әтил җире.

Тәүге тапкыр тәпи баскан туфрак
Башкортстан булган.
Күңелемә тәүге бию көе —
«Әпипә»ләр тулган.

«Пар ат»ларны ятлап
җырлаганмын,
Тукай «Пар ат»ларын.
Урал өне курай гына түгел,
Тальяным сакладым.
Балачакның гамьсез күзе белән
Караганмын җиргә.
Чын күңелдән мин бит
инанганмын —
Бу ике тел бергә
Арымас та, аерылмас та сыман.
Агыйдел һәм Чулман —
Икесе дә, күңелем буйлап агып,
Җан чишмәмә тулган.

Бүген килеп миңа әйтә кем ул?
«Чишмәң буталган,— дип,—
Елгаларның җанга агымнары
Янә тукталган»,— дип.
Идел агымнарын туктатырга
Әллә әмер бармы?
Халык күңеле әллә саеккан да
Җан ишеге тармы?
Җаным синдә минем, Татарстан.
Җирем — Башкортстан.
Кеше булып яши алырмынмы
Берсеннән баш тартсам?!

# *Белү кирәк...*

Беләсеңме, җилнең нидән искәнен?
Беләсеңме, күңел нидән төшкәнен?
Беләсеңме, ник әйләнә кояш вә җир?
Ник сөяләр бер-берләрен хатын-кыз, ир?
Белү кирәк!

Тукталмаса Җир шарының әйләнеше,
Өзелмәсә буыннарның бәйләнеше,
Үз вакытында килсә җиргә фасыллары,
Барлап торса кайсы киткән,
                                        кайсы барын —
Белү кирәк!
Җил исмәсә, яфрак төшми, беләсең бит.
Яфрак төшми көзләрнең дә киләсе юк.
Җил исмәсә, болытлар да күчмәячәк,
Болытлардан мамык карлар төшмәячәк.
Белү кирәк!
Ак карларга парлы эзләр салынмаса,
Шул көннәрне
                        гашыйк парлар сагынмаса,
Күңелләрдә булмаячак бер хәрәкәт,—
Шушы булыр төшенкелек вә һәлакәт —
Белү кирәк!



## *Хәлем шундый...*

Туган яктан чыгып киткән чакта
өзелде җан кылым.
Күңелем кеби нечкәрде дә шулчак
өзелеп калды юлым.

Яшь елгасы озата килде мине
олуг Казаныма.
Моңлы азан инде, шөкер әле,
бу үксез җаныма.

Туган җирдәй якын инде Казан,
моңлы, манаралы.
Шул моңнарда җаным тибрәтергә
милләтем бар әле.

Әмма...
Манаралар торып бассалар да,
шуышалар... җаннар...
Аяк өсте басма, иел! — диеп,
ысылдап торалар.

Казанымнан чыгып киткән чакта
тагы өзелер бер кыл.
Аягүрә басып каршы торыр
хәлем аңлап Идел.

Уралымнан, Иделемнән китеп,
тагы кая барыйм?
Хәлем шундый:
                ташлап чыккан кеби
Иделкәем ярын...

## *Әй, дөнья!*

Әй, син дөнья, дөнья, дөньякаем!
Синдә балкый моңсу айкаем,
Синдә яна минем кояшкаем,
Сөю белән тулы җанкаем!

Минем өчен язлар алып килдең,
Миңа алып килдең ташулар.
Минем җанда сиңа мәхәббәт тә,
Анда минем, синең ярсулар.

Бу дөньяның иң зур баедыр мин,
Җир оҗмахы — урман-кырларым.
Миллион-миллион яфрак теле белән
Урман җырлый минем җырларым.

Елгалары җаным аша ага,
Җанга бәрә дәрья сулары.
Сагышларым җыеп ай моңая,
Шатлыкларым — кояш нурлары.

Иң бәхетле миндер бу дөньяда —
Дөнья мине шундый ярата!
Минем сөюемне яңгыр итеп,
Ак кар итеп җиргә тарата.

Һәр бөредә минем садә хисләр,
Җилләрендә — минем офтану.
Арыганда бөтереп ала вакыт,
Гомерләрдә, юк, дип, тукталу.

Мин җир белән, мин җыр белән бергә
Әйлән-бәйлән уйныйм галәмдә!

Дөньялыкта сүзем калдырырга
Ходa биргән, шөкер, каләм дә.

«Мин — иң зур бай,
мин бәхетле!» — диеп,
Оран яңгыраган бер мәлдә,
Җаны кайтып, яфрак ярыр сыман
Шатлыгыннан яшел әләм дә!

## *Арала!*

Кешеләрне шундый яраттым мин:
Җырлар багышладым аларга.
Җырладылар алар ул җырларны,
Моңнар акты сыймый ярларга.

Кешеләрне шундый яраттым мин:
Гафу иттем барысын аларга.
Алар шундый ямьсез кыландылар:
Нәҗес акты сыймый ярларга.

Кешеләрне шундый яраттым мин:
«Кер,— диделәр,— безнең арага».
Нәҗес тулы ярда басып торам —
Бата күрмим, Ходам,—
арала!

# *Урман шаулый*

Син шаулама, син кычкырма, диләр.
Син акыллы, түгел юләр диләр.
Җырла, диләр, бары мәхәббәтне.
Һәм кузгатма җанда җәрәхәтне.
Шауламаска, шауламаскамыни? —
Безгә ирек дауламаскамыни?

Шауламаска дию, бәлки, хактыр,
Йөзгә сөрткән корым, бәлки, актыр?
Тик мәхәббәт булсын җырың, диләр.
Менә шундый синең чорың, диләр.
Шауламаска, шауламаска, диләр,
Колга ирек дауламаска, диләр.

Әйе, чорлар һәммәбезгә чыдар.
Чорлар ярын тутырып ага җырлар.
Һәрбер чорның җирдә язы бар,
Шагыйрь, шуны гына яза бар!
Ел фасылы, диләр, яз гына,—
Шауламый тор, диләр, аз гына.

Агачларда бөре ачылганда,
Кешеләрнең җаны ачынганда
Шауламаска, бәлки, кирәктер? —
Әмма һәммәбездә теләк бер.
Шулай булачак ул, шулай булган,
Шауламыйча буламыни урман?..

## *Мин яшь чакта...*

Мин яшь чакта
дөнья матур иде,
кеше батыр иде.
Яши торгач, дөнья
сүрәнләнде.
Кеше бахыр инде.

Мин яшь чакта
әкрен йөри иде
хәтта трамвайлар.
Хәзер ашыгалар,—
мин килгәнне
көтеп алалмыйлар...

Мин яшь чакта
бары сөеп кенә
карый иде күзләр.
Хәзер әллә ничек
кырысланды,
ямьсезләнде сүзләр.

Мин яшь чакта
егет
бер кашык су белән
йотар солтан иде,
хәзер менә
хәмерләрдә йөзеп
йөргән олтан инде.

## *Бу — ир, бу — ил...*

Күктә кояш,
ә күздә яшь —
Җиңүчеләр елый.
Шатланырга
иде, кана,
Йөрәк кенә яна.

Туган җиргә төшкән
кисәү төтәп ята,
Кем кулында
кисәү булдык соң без?
Уйлыйм шушы хакта.

Күктә кояш,
табан астында җир.
Туган-үскән җирем.
Рәхмәт, сакладың, дип
кочып алган
Хатын гарип ирен.

Ике аягы да,
кулы да юк.
Җир күк янган йөзе.
Киселгән тел,
киселгән уй,
Ә бар әйтер сүзе...

Аяк-кулы, теле кисек бу ир —
Илнең бит нәкъ үзе...

## *Әй, Туган тел*

Әй, Туган тел, бәйләнгәнсең
Җанымдагы һәрбер хискә.
Фани дөнья йөзләрендә
Мин эшләгән һәрбер эшкә.

Әй, Туган тел, бәйләнгәнсең
Уйларымның һәр очына.
Хәтта бәйсез дип уйлаган
Зәңгәр күкнең һәр кошына.

Әй, Туган тел, бәйләнгәнсең,
Тамырларга бәйләнгәнсең;
Син аларны яшәтүче
Яфракларга әйләнгәнсең.

Бәйләнгәнсең искән җилгә,
Тәпи баскан туган җиргә.
Әйләнгәнсең Иделемнән
Җанга аккан олы җырга.

Әй, Туган тел, бәйләнгәнсең
Урамга да, Уралга да.
Себерләрне Себер иткән
Ап-ак карлы буранга да.

Бәетләргә бәйләнгәнсең,
Әкиятләргә әйләнгәнсең.
Мәңгелеккә бару юлын,
Туган телем, шәйләгәнсең.

Әй, Туган тел, әй генәм лә,
Җанны җанга, җирне җиргә,
Җырны җырга, серне сергә
Бәйли торган бәй генәм лә!..

# *Идел, Иделкәй, сагай!*

Илдә ниләр бар икән:
Юллар зәңгәр кар микән?
Һавадагы алсу шәүлә
Пожар микән, таң микән?

*Хәсән Туфан*

«Һавадагы алсу шәүлә
Пожар микән, таң микән?»
Без бу илдә шул сорауга
Җавап табарбыз микән?

Сугышлар игълан ителми,
Туплар атыла гына.
Корамалар гына түгел,
Җаннар ватыла менә.

«Кузька анасы»н күрсәтеп,
Куркытмакчы булалар.
Таулар бетләми бит соң ул,—
Ник тауларга тулалар...

Борчаны дагаласаң да,
Дагалап булмый җанны.
Рәсәй туплары астында
Шәһит киткәннәр җаны
Кол булганнар саны түгел,
Кол булмаганнар җаны
Ирек кояшын күтәрә,
Аттыра бүген таңны.

Үз җирендә үзе булып
Яшәргә тели халык.
Ышандырырга телиләр:
Сез халык түгел, балык.

Ятьмә салып, тотып алып,
Коллыкка җикмәкчеләр,
Чуртан кушуы буенча
Гел гомер итмәкчеләр.

Җан кушканча яшәр идем,
Ау корылган җаныма.
Янгын шәүләсе күбрәк
Таңнарым алсуында.

Ә без һаман да «бер көйгә»
Агабыз әле, агай...
Тау җилләре пышылдыйлар:
Идел, Иделкәй, сагай!

## *Туган телемдә*

Телемне ачкан тәүге сүз —
Әнкәй һәм әткәй.
Ние бармы ул сүзләрнең,
кай бала әйтми?

Җанымны ачкан тәүге сүз —
«Сине яратам!»
Әйтелгәндер инде бу сүз
кемгә карата?

Әнкәйгә дә, әткәйгә дә,
Әби, бабайга.
Чәч толымнарымны тартып
киткән малайга.

Әйтелгәндер синең эзләр
калган урамга.
Чәчләреңә көмеш карлар
салган буранга.

Әйтелгәндер Иделемә —
Туган илемә.
Синең өчен чәчәк аткан
зәңгәр гөлемә.

Әйтелгәндер Уралыма,
очар кошларга.
Бит очларын чиметә торган
салкын кышларга.

Язларына, көзләренә,
җәйләренә дә.
Туган телдә җырлап аккан
Әйләренә дә.

Агыйделгә, Карыйделгә,
Бүә суына.
Әкиятләрдәй җанга сеңгән
Сабан туена.

Җиленә дә, давылына,
сагышына да.
Зәңгәр күлнең керфекләре —
камышына да.

«Яратам!» — дидем барсына
туган телемдә.

Әткәй, әнкәй, әби-бабай,
Тукай телендә.

Туган телдә әйтелгәнгә
бар да ишеткән! —
«Саумы, әнкәй!» — диеп керә
балам ишектән.

## *Туган тел — намаз*

Әбием минем, әбием минем!
Ул киеп йөри борынгы кием.
Аның күлмәге алсу ефәктән,
Вак-вак бөрмәләр матур итәктә.

Йомшак камзулы чия төсендә.
Әбием көн дә намаз өстендә,
Чәчләре кебек ап-ак яулыгы,
Аллага шөкер әле саулыгы.

Икәү көн саен җырлыйбыз
бер җыр,—
«Туган тел» җырын
язган зур шагыйрь.
Аның исеме — Габдулла Тукай.
Бу хакта хәтта белә ди Ходай.

Ачыла күзем, чәчелә йокым,—
Мин намазлыкта
«Туган тел» укыйм.

# *Идел — ил уе*

Һаман әйтәләр: түз дә түз!
Без тыңлыйбыз, түзәбез.
Корбан өчен үстерелгән
Сарыклар түгелме без?

Тарихның язы килде дә
Җылынды җирдә һава.
Бозлы карлар белән бергә
Тымызык яңгыр ява.

Кыеклардан сөңге бозлар
Юнәлгән җиргә түбән.
Сөңгеләр кадалуыннан
Сүнгән йөрәкләр күбәү.

Җирне үзгәртеп корырга
Теләгән иделәр дә,
Үргә агарга карышты
Дулкыннар Иделләрдә.

Буылган буалар гына
«Үзчирле» булып чыкты:
Үзенекен итте ташкын —
Каршы басканны екты.

Иделне күпме будылар,
Тик тукталмады Идел.
Идел — ил уе, аңа соң
Богау чыдамасын бел.

Җәелде Идел, ярына
Төзелгән утарларны
Агызды да алып китте,—
Җирдә соң урын тармы?

Бәргәләнеп акты Идел,
Чаларды ачуыннан:
«Үз ярлары булмаганнар
Тартамы чабуымнан?

Нигә минем ярда алар?
Ник ябылган киртәгә?
Чалынасын белмиләрме
Корбан булып иртәгә?»

Идел булып Идел яна,—
Без дәшмибез, түзәбез.
Корбан өчен үстерелгән
Сарыклар түгел лә без?..

## *Сыгылу*

Төнге тынлык,
Көзге чынлык,—
Яфрак төшә җилсез дә.
Кыш буе сызгырыр агач,
Яшәп торыр телсез дә...

Көзге тынлык.
Без дә тындык.
Шигырь язам телсез дә...
Ничә гасырлар яшәдек
Дәүләтсез дә, илсез дә...

Көзге тынлык,
Җил дә юк.
Уелыплар китәм бит.
Тарих тора әйләнеп,
Ә без һаман бәйдә бит...

## *Мин дәшмәдем...*

Мин дәшмәдем,
Әнә еллар шаһит,—
Әйтер сүзләр катты таш булып.
Еламадым — түгелер яшьләремнән
Тау-тау үсеп чыкты ак болыт.

Көлмәдем дә,
Әнә кояш шаһит.
Шатлыкларым якты кояшта.
Кырык яшьтә сабый бала кебек
Буыламын бүген күз яшькә.

Ак болыттан бүген яшьләр түгел,
Таш-таш сүзләр җиргә коела.
Әллә чынлап шулай, әллә инде
Миңа гына шулай тоела.

Таш-таш сүзләр өскә коелганда
Тетрәүләрне кая куясың?..
Үз-үзеңне эзләп табар өчен
Ташларга да сүзләр уясың.

Аһ, бу ташлар,
шагыйрь хисләреннән
Хасыйл булган ачы җаннардыр.
Шуңа күрә шагыйрьләрнең җанын
Бары ташлар аңлый аладыр.



# *Йөрәк кысканда*

Саумы, көн, дип күзем ачам иртән.
Саумы, диеп, дәшә миңа иркәм.
Кояш нурын мин сак кына тотып,
Кешеләрнең җаннарына чиртәм.

Саумы, син, дим, хәерлеме иртәң? —
Хәвеф тулы күзен ача иркәм:
Нихәл генә итик, ул ни откан? —
НАТО Косовоны тупка тоткан.

Тоткан нурым кулым өтеп ала,
Миңгерәеп торам мин берара.
Радио сөйли: мәетләр йөз...
Калганнары... бөтен иле яра...

Кара диңгез буйлап кораб бара,
Сугыш барган якка үз теләге белән
Сугышырга иреклеләр бара...
Иреклеләр? Сугышырга бара?

Иреклeдән сугышалармыни?
Качалармыни соң үз төяктән?
Шушы ялганнарга чыдый алмый,
Саркып тора кан-яшь йөрәктән.

Көнем сүнә... кулга түгел, күзгә
Кояш нуры керми, сүрелә.
Кеше хакына дип үтерүләр
Менеп җитте заман түренә.

Түргә менде, түрдә телевизор,—
Анда — зина, анда — үтереш.
Монда менә, монда — башка дөнья,
Ачлы-туклы гына көнкүреш.

Ул экранда үлем — уен гына.
Димәк, яшәү — уен, яшәү дә?
Саумы көн, дип, күзем ачсам бүген,
Бар саулыгым икән дәшмәүдә...

Өзгәләнеп дәшәм мин кояшка,
Элеккечә кояш, ул яна...
Төнгә калам, айга багынам,—
Мин хәерле көнне сагынам!

Саумы, диеп, дәшәргә дә куркам:
Таң җилендә бала үксүе.
Кояшта — кан, айда — җан әрнүе.
Җир калтырый, агу — күк, суы.

...Сәясәткә кермим... Юк, кердем ди,
Сәясәт ул пычрак, мин «чиста!»
Сәясәткә кермәс өчен генә
Качып бара илдән бу кош та...

Саумы, көн, дип, инде дәшә алмыйм.
Ничек инде үз-үземне алдыйм?
Сәясәткә кермим, кирәкми...
Косовода сабый үлеп бара,—
Аңа өзеп бирәм йөрәкне...

Нәрсә дим соң? Нәрсә дим соң? — дим дә,
Уйлап куям йөрәк кысканда:
Шул ук хәлне әзерләмимени
Бүген Мәскәү Башкортстанда?
Без әйтәбез язмыш кушканга?!

Сәясәткә кермим, тик сорыймын:
Сәясмәннәр, кая барасыз?
Кайчан соң рух — Алла, ә акча — чүп,
Җаннар булыр икән ярасыз?
Кайчан?!

# *Кеше һәм кош*

Кошлар сайрый,—
Әллә сайрый гына?
Сагышлардан кош та үксидер.
Әллә кеше генә парын җуя,
Кошларда да ансыз үтмидер.

Кошлар оча —
Әллә кошларның да
Җәяүлесе юкмы, бар бит ул.
Тәвәләрнең иңрәүләрен тыңла,—
Җәяүледә моң да зар бит ул.

Кош һәм кеше,
Әллә икесе дә
Бер үк җирне кочып аумыйлар?
Егылырга әгәр җирең булса,
Егылганнарны да аңлыйлар.

Кош каберсез,—
Әллә кешеләрнең
Каберләре һәрчак табыла?
Кошлар булып җиргә кайта кеше,
Оча алса кеше чагында.



# *Таш хәтере*

«Ленинградцы — дети мои».
*Джамбул*

Гаҗәп түгел, бары шатлык кына
Алыштырса кышын, язларын.
Яшеллеккә сары сагыш сибеп,
Килеп җитә икән көз тагын.
Мондый кабатлану яшәешне
Чыныктыра һәм дә чын итә,
Салкыннарның җанын эретә дә,
Язгы ташкын ярсу чың итә.
Әмма гаҗәп шундый кабатлану:
Блокада. Ачтан җан бирү.
Көрәк сабы төртсәң, яфрак ярыр
Туфрагында ачтан тилмерү.
Бүген килеп тагын кабатланды —
Алыштырды көнне кара төн.
«Чичнә — минем балаларым!» —
диеп,
Әйтерсеңме бер көн, син, Путин?
Таш тамырсыз диеп ялгышабыз,—
Йөзем чыбыккаен дым тарта.
Тауда ташны ваткан саен ачу,
Ташны уйган саен уй арта...
Тамыр кисеп, яңа кала салып,
Тауларда мы яшәп калмакчы?
Таш хәтере көчле, чорлар аша
Аваз салачаклар: алдакчы!
Таш хәтере каты, катлы-катлы!
Ташны сыгып суын эчеп кара!
Терексуы хәтерендә бүген
«Үлем» дигән агым агып бара.
Тауга түгел, агым түбән ага...

## *Алай дисәң...*

Илегезне ташлап китәм:
Илегез иләс-миләс.
Кемнедер утта яндыра,
Кемгәдер рәхәт, җиләс.
Ташлап китәм, таш арасы,
Сап-салкын таулыкларга.
Менәрлек биеклеге дә,
Сугышыр киеклеге дә,
Ташланыр упкыннары да,
Табыныр сафлыклары да,
Миндәй илен ташлап киткән
Мәңгелек Сак-Соклары да —
Барысы да булсын ул илдә,
Тик сез генә булмагыз,
Күңелләрем бушлыгына
Нәҗес булып тулмагыз!

Китәм буп-буш далаларга,
Күмеләм сары комга,
Калмады бит әйтер сүзем
Сезнең ямьсез токымга...

Шундый таулар иле кирәк,
Юк, кирәкми тигезлек.
Бәдрәф корты тавыш бирә:
«Мин дә сиңа тигез»,— дип.
Әгәр дә тигезләнмәсәң,
Риза булмасаң шуңа,
Рухи зынҗыр кидертеп ул
Тәмуг утына сала.

Илегезне ташлап китәм,
Айга китәм, кояшка.
Китәм диңгезләр иленә —
Тоз, су булып туарга,
Үсемлек булып үсмәскә,
Кыелмаска, каерылмаска,
Тамырымнан аерылмаска,
Янмаска, киселмәскә —
Алай дисәң,
Буленә купмегә тоз,
Киселә купмегә сүз.
Буыла һаман сулар —
Бу миндә ялгыш уйлар?

Тик риза булсаң язмышка,
Юл ачыла ялгышка —
Карап торам балкышка:
Минем бит күзләрем бар.
Киселсә дә ялганырлык
Теп-тере сүзләрем бар —
Күз,
сүз,
түз!!!



* * *

Әй тын иде,
Әй чын иде
Монда яшәеш, мохит.
Теләсәң, үс, ирек иде,
Берсендә дә юк хөсет.

Каен, имән,
Тупыл, шомырт.
Чүп агачы — вак чаган.
Бала-чага әлә иде
Җәй көннәрендә таган.

Саз суларын
Эчә-эчә
Күккә ашты тупыллар,
Тупылларга вак агачлар
Инде ясин укыйлар.

Үргә акмый,
Күккә ашмый,
Басса да су сыннары.
Яшел шау гына бит бары,—
Юк тупыл утыннары.

Утынсыз агачлар кебек
Азмыни китүчеләр.
Утсыз-уйсыз яшәп кенә
Китүне көтүчеләр.

# *Табигать тә әгәр алдаса...*

*(Салкын язда)*

Алдауларга күптән күнеккән мин,—
Алдый дәүләт, алдый хөкүмәт.
Алдый нәшер, алдый мөхәррир.
Алдап китә хәтта хәләл ир.
Урам чатларында хәерчеләр
Аракыга алдап җыялар.
Ә банкирлар безне алдый-алдый
Процентлардан тәхет коялар.
Сөте майсыз, хәтта мае майсыз.
Май ае да быел алдады, —
Безгә ел да биреп бара торган
Май җылысын бирә алмады.
Алмагачы чәчәк аталмады
Май аеның унбишләрендә.
Табигать тә әгәр алдый калса,
Агай-эне, белмим, нишләргә?
Тупылларда яфрак яшел түгел,
Әллә майдан кердек көзләргә?
Ялганнарга ялганламаенча
Сары чыкты инде йөзләргә.
Сары яфрак коя майда тирәк,
Юк бөрегә кайту киредән.
Кай җиребез белән артык соң без
Ачылалмый сулган бөредән...
Бөре сулган, исән тик өмет,—
Җылы җил бер исәр, көт! көт! көт!



## *Бүген инде утыз бере*

Җаным тулы шатлык була иде,
Яңа еллар җиргә якынлашса.
Әй, кайгыра идем — җир өсләре
Яуган кардан әгәр ак булмаса.

Берьялгызым озата бара идем
Иске елны соңгы минуткача.
Каршы ала идем өр-яңасын,
Керфек какмый янә таң атканчы.

Яңа яуган карга ал нур ята,
Кар кызларын куыра салкын җил.
Салкыннарны сөеп, китә алмый
Калган кошкайларның хәлен бел!..

Җилне ишетеп җимнәр сала идем,
Көттермичә кошлар ала иде.
Мин бәхетле идем яңа елда,
Үз бәхетем белән кала идем.

Хәзер менә белмим, нинди җилләр
Керәләр дә җанны туздыралар.
Шатлыкларны, белмим, кая куып,
Кайгыларны түргә уздыралар.

Кар авырдан түгел, ачы зардан
Шәм наратлар башын түбән игән.
Әйтерсең лә бүген бөтен дөнья
Иске кайгыларны иңгә өйгән.

Ялгыз чагым якты булган икән,
Һәм дә аграк булган икән карлар.
Ярым бар, дип сөенерлек түгел,
Кара хисләр өстәп торгач алар...

Таптым, диеп иртә сөенгәнмен —
Тапкан гынам булды кара тап.
Әй, иске ел, зинһар, яңа елны
Уздырмыйча торчы, капкаң яп!

Шатлыкларның искеләрен саклап,
Көч-хәл белән җанны бикләп торам.
Җангынамда ел әйләнә кышлар —
Хет яңа ел бирсен иде юрган!..

Юрганнарга төреп шул җанымны,
Еракларга, бәлки, китәр идем.
Ышандырып, бәлки, үз-үземне
Бәхетемне шунда көтәр идем.

Әмма бүген инде утыз бере,
Үтәлмәгән йөз теләкнең бере.
Ә теләкләр шундый гади иде,
Мин мәхәббәт көткән сабый идем.

Бүген инде, бүген утыз бере.
Минем җаным ачылмаган бөре...

## *Яз булгач...*

Җан түгелгәндә
мин — яз!
Җан фәрман бирә:
яз! Яз!
Түгелә җан
яз булып,
Һәр тарафтан
наз булып.
Алай ярамый,
диләр.
Яз булгач,
нишлим, юләр?
Үбеп алам
бөрене.
Бер яфраксыз
шүрене.
Алай ярамый,
диләр.
Язганда, нишлим, юләр!
Ташкын булып та
агам.
Ялкын булып та янам.
Җимерәм
ярларны да.
Ишетмим
зарларны да.
Алай ярамый,
диләр.
Яз булгач, нишлим, юләр!
Җан түгелә —
мин гашыйк.

Йөрим җилләрдәй
шашып.
Җан фәрман бирә:
яз! Яз!
Әле болар да
аз! Аз!
Җиргә шытам
гөл булып,
Уттан калам
көл булып.
Мәхәббәттән яна яз.
Җан фәрман бирә:
яз! Яз!
Акылдан язма,
диләр.
Язганда мин дә юләр!

## *Ялгыз уксү*

Үксү булып чыга җаннан әрнү.
Үксү булып кабат җанга иңә.
Офтанулар булып искән җилләр
Ниләр генә сөйли ала сиңа?

Тозлы ташкын булып чыга әрнү,
Өтеп-өтеп ала яраларны.
Тамчы гына булып тамсалар да,
Күз яшьләре уя араларны.

Үксү булып җаннан чыккан әрнү
Үксү булып кабат җанга кайта.

Кысып калалмасам җан гынама,
Барып бәрелер иде алар айга.

Әрнү-сагышлардан тулган айның
Җаны ярылыр иде түзәлмичә.
Моң туфаны җирне басар иде,
Ай ярасы торса төзәлмичә.

Ялгыз айның күз яшьләре таммый,
Тик ялгыз ай барыбер мине таный.
Синсез үткән кара төннәремнең
Минут-секундына кадәр саный.

Тып-тып итеп тама күз яшьләрем.
Тып-тып итеп хәбәр бирә йөрәк.
Үксүләрдән арта гына әрнү.
Инде күз яшьләрем тама сирәк.

Күкрәп килеп яшен камчылары
Җан гынамны ничек камчылады!
Җиңелрәк булыр, ела, диеп
Әйтергә дә мөмкин кайсылары.

Бушанып та калган кебек бу җан.
Ә буш җанга җирдә бармы соң сан?
Үксү булып җанга әрнү иңә.
Һәм... алар да берни әйтми сиңа...

# *Үз иркем — ирексезлек*

Признаюсь: я жил.
*Пабло Неруда*

Үз иркем белән адашам
Кереп карурманнарга.
Исем дә китми туктаусыз
Бүреләр улаганга.

Үз иркем белән адашам,
Бураннар күмсен иде.
Буран дулап, бүре улап,
Оныттырачак сине.

Язгы ташуларга төшәм,
Агызып китсен иде.
Мәхәббәт уты сүнгәнне
Ул кабул итсен иде.

Ярга ташлады ташкын.
Тынды урман, шауламый.
Кушылыплар улар идем,
Ник бер бүре уламый...

Җанда кабынган янгынны
Юк сүндерү чарасы.
«Мин сөйдем —
җәзала!» — диеп,
Бер Ходага барасы.

# *Йөрәкне йөгәнләү*

Йөрәк сүзен әйтеп тора:
Чыгар мине читлектән!
Бар микән дөньяда тагын
Минем кебек интеккән?

Читлеге белән йөрәкне
Кыстым да учларыма,
Ышандырдым үз-үземне
Килдем дип һушларыма.

Йөрәк йөгәнле килеш тә
Үзенчә атлый икән.
Кабат ачтык — су барыбер
Үрләргә акмый икән...

Шул йөрәк кушуы белән
Битләр тиде битләргә.
Җимерә генә алмадык,—
Ачу килде бикләргә...



## *Давыл биеклегеннән*

Өстәлемнән китә алмыйм,
дәшеп тора.
Ак кәгазьгә төшәр хисләр
ташып тора.
Кулларымнан каләмемне
куя алмыйм.
Синең хакта гына язып
туя алмыйм.
Сиңа язган хатларымны
давыл ала.
Сүзләр генә җилгә оча,
хисләр кала.
Давылларның биеклеге
күпме икән?
Давыл йолдызларга барып
җитми микән?
Ах, бер йолдыз минем хатны
укый алса,
Бар галәмгә хисләремне
ачып салса...
Шул хисләрне җыям диеп,
йолдызгача
Шул мизгелдә һушын җуеп
берәү очар.
Ә син һаман җәяү генә,
ава-түнә...
Канатлы хис шушы хәлгә
әллә күнә...



* * *

Кояшым кебек түгәрәк иде сагышым.
Кагылдың да боздың менә уйлар агышын.
Ай шикелле ялгыз идем йолдызлар өчен.
Ялгызлыгымны бозарга җитте шул көчең.
Җилләрдәй ирекле идем мин вайраннарда,
Бүген җаным бәргәләнә шул араннарда.
Сыңар яр — мин,
сагышлардан кабынмас өчен.
Чит ярларга ялгышыплар табынмас өчен
Агымсуны сыңар ярга кысып күл иттем.
Син билисе урыннарны комлы чүл иттем.
Кояш кебек түгәрәк күл өсте — төнбоек,
Сыңар ярда яшәгәнгә күлләр гел боек.

## *Гыйсъян тынлык*

Бүген өйдә шундый тынлык,
Юк, өйдә генә түгел,
Яфрак селкенер җил дә юк,
Юк, тышта гына түгел,—
Җан вәйран, чиге күренмәс
Дала, юк, чиксез галәм.
Тынлыкны бозудан куркып,
Тукталып калды каләм...

Бүген минем өй ишеген
Юк, ачып кермәс беркем.
Җанга бирәр җан дәшмәсә,
Эзсез югалыр бер көн.

Җан югалткан көн озын ул,
Бер гомер кадәр озын.
Тынлык шулкадәр мәкерле,
Тынлык шулкадәр түзем...

Тәрәз каршында алмагач,
Дөнья тын да алмагач,
Төшерде бер алмасын,—
Башка берәү алмасын...

Алсын, алсын алмасын,
Алсын, нигә алмасын,—
Минем кебек тынлыкларда
Ул адашып калмасын.

Туп-туп итеп ике аяк
Бозды урам тынлыгын,—
Алды да тешләп карады
Алмасының чынлыгын.

Пешкән алма пешкән шул,
Өзелепләр төшкән шул.
Пешмәгән алмасы — мин,
Өзә алмаганы — син...

Тәки дәштең җаныма,—
Тагы боздың тынлыкны.
Кайларга гына куярга
Дөньядан бу чынлыкны?

Беркемне дә көтмәгәндә,
Җаныма кертмәгәндә,

Кояш тынлыкны бозмыйм дип,
Карны эретмәгәндә,
Алма тешләгән сандугач
Томшыгын кысмаганда,
Дөп-дөп итеп таптанасың
Син җаным почмагында.

«Сандугачым алма тешли,
Тешләсә дә кабалмый шул.
Минем күңелем сине эзли,
Эзләсә дә табалмый шул».

Тынлык тына, тынлык сына,
Тынлык түзем түгел шул...
Сине югалтканнан бирле
Үзем үзем түгел шул...

Тынлыклар гел шаулап тора,
Кычкырып тора тынлык:
Сиңа ансыз, аңа синсез
Дөньяда юк ул чынлык.

## *Эзләп барам*

Көнем шундый иртә сүнде,
көн уртасында.
Кызарды да батты кояш
аш туртасыдай.
Юкса кайнап кына чыккан
иде бу хәят.
Җанны арбап алган иде
олы мәхәббәт.

Көн уртасында кояшым
китте күгемнән.
Күңел ярларыннан ташып
хисләр түгелгән.
Иярен таба алмый
адашты хисләр.
Мәхәббәтен табалмаган
бу җаным нишләр?
Җир өстендә, җир астында,
җир аръягында
Мин мәхәббәт эзләячәк
икән тагын да.
Ансыз кайда яшәү мөмкин? —
белми кешелек.
Шул мәхәббәтне тапмыйча,
мәңге өше дип,
Кем каргады икән мине?
Әллә Алламы?
Ул да вөҗданына каршы
бара аламы?
Җир йөзендә бервакытта
сүнмәгән көнне,
Мине сөюдән һичвакыт
туктамас кемне
Җир өстеннән, җир астыннан,
җир аръягыннан
Эзләп барам, әйтәчәкмен
мин тапкан көнне...

# *Елау җыры*

Китүләрнең ни икәнен беләм.
Көтүләрдән күпкә түбән гамәл.
Калмагандыр инде бүтән әмәл
Сөюеңне сыйдырмаган белән.

Тик барыбер таңнан китәлмисең.
Күзләреңә ул мин булып карый.
Таң җилләре чәчләреңне тарый.
Син җилләрне урап үтәлмисең.

Көн шау-шулы, ансыз үтеп китә.
Егыласың кереп безнең төнгә.
Сугышасың кайтмас өчен өнгә,
Тик төнебез сине үги итә.

Төшләреңнән сине суырып ала.
Ташлап китә тагы безнең өнгә.
Ашыгасың, тизрәк-тизрәк төнгә.
Һәм безнең ай сине куырып ала.

Көтүләрнең ни икәнен белә,—
Ай бер гомер генә көтәмени?
Чынлап сөйгән ташлап китәмени?
Мин сөюнең беләм ни икәнен...
Ай шул күреп тора кем киткәнен.
Ай белә шул кемнең кем икәнен...



# *Яратам*

Мин яратам.
Туган һәрбер иртәм
Миңа шулай гүзәл күренә.
Әйтерсең лә мине уздырганнар
Оҗмахларның татлы түренә.

Мин яратам.
Яшел яфракларның
Үбеп йөрим буем җиткәнен.
Сагынырга хәтта вакыт калмый
Гомеркәйләремнең үткәнен.

Мин яратам.
Кеше гайре гүзәл,
Ис-акылым китә шуңарга.
Нидән шулай, әллә бу дөньяга
Рухи гашыйк булып туганга?

Мин яратам!
Урам песиләрен,
Яратамын урам этләрен.
Гаҗиз калам, әгәр барсыннан да
Мәңгелеккә китсәм, нишләрмен?

Мин яратам!
Артык яратам шул!
Елап, көлеп, үлеп яратам.
Каеннарның тамырларын кочып
Ятачагым белеп яратам.
Я-ра-там!

# II

*И күңел, бил баглама, күпне кичергән дөньядыр.*
*Бу үлем ширбәтен халыкка эчергән дөньядыр.*
*Син сыгылма дөньяда мин бакый калаем дип.*
*Күп янар вакытта чыракларин үчергән дөньядыр.*
*Углыны атадан аерып, кызны анадан аерып,*
*Еглатып бер-бер ишектә зари кылган дөньядыр.*

Колшәриф
(XV йөзнең азагы — 1552)



# *Татар җаны*

Татар җаны, инде синең өчен
Әверелү чоры күптән үткән.
Татар җаны инде гәүдәсеннән
Үзен-үзе ничә тапкыр түккән.

Агымсулар булып аккан ул җан,
Давыл булып күккә күтәрелгән.
Каф таулары булып торып баскан,
Әллә ничә тапкыр түнтәрелгән.

Кыр казлары булып очкан ул җан,
Йорт казлары булып җиргә төшкән.
Язда канат исе килә, диләр,—
Кыр казында татар җаны икән.

Әмма әверелергә кирәк әле,
Әверелергә кирәк чуер ташка.
Таш булырга, баш булырга кирәк
Безгә Хода биргән зур язмышка.
Мәңгелектән шулай аерылмаска.



## *Булуы кыйммәт*

Син үзеңнең зурлыгыңны
бел, диләр миңа.
... «Мин — зур!» — дисәм,
кычкыралар:
— Ни җитми сиңа?
Ә миңа бит зурлык түгел,
милләтем кирәк.
Ә ул булса, яшибез без,—
булуы кыйммәт!

## *Кызлар гимназиясенә гимн*

Язмышыма язлар булып керде
Мәгърифәтле бина — гимназия!
Ул бүген дә киләчәкне саклар
Гали җанлы балаларны җыя.
Мәгърифәтле бина — гимназия!

Җылы эзләп сиңа сыеначак
Затлы татар халкы йолалары.
Олуг хатын-кызның җаны булып
Челтер-челтер ага елгалары.
Мәгърифәтле бина — гимназия!

Бөреләре язның ачылачак
Тагын-тагын синдәй кошлар булып.
Татар бакчасында сайраячак,—
Сайраячак сайрар кошлар кунып.
Сандугачлар тулы гимназия!

Карурманнар булып шаулаячак
Яңгыраячак әле синдә моңнар.

Идел–Йортка үзе ана булыр
Бүген монда укыр кыз балалар.
Ана нуры тулы гимназия!

Зирәк акыл, илче теле белән
Сөйләр кызларны ул бүген җыя.
Татар язмышына яз китерер
Айлы, атлы, затлы гимназия!
Мәгърифәтле, нурлы гимназия!

## *Үз ягына бора*

Хаклык эзләп халык ханга барган.
Хаклык эзләп барган хаҗга да.
Хаклык белән халык арасына
Ялган сыя алмый азга да.

Капчыктагы без генә түгел ул,
Гасырларны тишеп кайта бит.
Алтыннарны ваклап бетерәләр,—
Хаклык бөтен килеш ята бит.

Бөтен килеш ул бөтереп ала
Ялагайны йә шул явызны.
Әйттермәскә һаман богаулыйлар
Кул-аякны, хәтта авызны.

Авызларга йозак салынгач шул,
Халык бераз дәшә алмый тора.
Хаклык дигән ачкыч
барыбер кайтып,
Йозакларны үз ягына бора.

## *Уянгач, аңларсыз*

Йоклыйлар
Төн буена да.
Таңны да күрми алар.
Иртәнге кояш нурлары
Җаннарга керми кала.

«Йоклыйбыз
Йокы туйганчы»,—
Дип, шуннан мактаналар.
Рәхәт яшибез, дип, шулай
Урында таптаналар.

Йоклыйлар,
Күзләре йомык
Гүзәллек, ямьнәренә.
Җаннары йомык, битараф
Дөньяның гамьнәренә.

Бүген күрми
Калган кояш
Иртәгә чыгар, диләр.
Йоклыйлар, әллә вакытны
Кирегә чигәр, диләр.

«Йоклыйбыз
Йокы туйганчы»,—
Сезнең чәйнәгән сагыз;
Барыбер уяну килә,
Килә ул —
Онытмагыз!

## *Язмышыңа үзең Алла бул!*

Һәммәсенең күңелендә бу уй,
Бу уй һәммәсенең телендә,—
Әйтә алмый, бик тә әйтер иде,
Хуҗа түгел ул үз илендә.

Алла, диеп, Алла, Алла, диеп,
Дәшә гаделлекнең үзенә.
Язмышыңа үзең Алла бул, дип,
Карап тора Хода күзенә.

Һәммәсенең күңелендә бу уй,
Бу уй һәммәсенең телендә.
Әмма түзә татар, һаман яши
Ата-бабасының көлендә...

Сөякләре, көле генә җирдә,
Ә җаннары, рухы галәмдә.
Үтә күренмәле корым булып
Яши алар безнең каләмдә.

Төссез каләм белән язабыз да
Үз-үзебезне һаман сызабыз.
Күңелләрдә зиндан тапкан уйдан
Инде ничә гасыр сызабыз.

Сорап куям, бәлки, әйтер диеп,
Бәлки, язар диеп каләме?
Мәңге шулай төссез яшәп булмый,
Тапмаганмы диеп әмәлен?

Күзләр мөлдерәмә күккә карый,
Ә тел авыз дигән зинданда.
Татар кадәр бармы түзем халык,
Бармы бирәр матдә җиһанда?

Һәммәсенең күңелендә бу уй,
Бу уй йөри бөтен җиһанда.
Ул уй уеп, кыеп төшерерлек
Җир-җыр дигән ярга җыйганда.

«Җыелмаса, җуеласын белсен!» —
Ата-баба рухы дәшәме?
Туган җирең бир дә баскыннарга,
Асылынган хәлдә яшәме?

Һәммәсенең күңелендә бу уй...
Нигә бу кадәрле моңсу ай?!
Кеше булып җиргә тәпи баскач,
Рухи өрәк булу ярамый!..

Куркалар һәм куркыталар алар:
«Үз җирендә татар исән,— дип,—
Җиһандагы ата-бабаларның
Рухи җебен җирдән кисәм!» — дип.

Нәсел агачының яфрагы без,
Коелабыз һәрбер көзләрдә.
Коелу түгел, кыелулар аша
Сары чыкты инде йөзләргә.

Ата-баба рухы нур җебенең
Нечкәрүен сизәм, сизәбез.
Оҗмахмыни баскын аяк асты? —
Ни хакына болай түзәбез?!

Җирдә Идел булып агабыз да,
Күк йөзендә моңсу ай булып.
Идел белән күкне тоташтырган
Яңгыр булып ява ак болыт.

Килә калса әгәр корылыгы,
Яумый торса яңгыр-элемтә,
Хурлыкларын кая куярсың соң,—
Авыр иде җанга элек тә...

Бабаларның рухын тоташтырган
Соңгы җеп тә чертләп өзелсә,
Кулың сузып, үз икмәгең сорап,
«Аңа» барачаксың җык килсә...

Һәммәсенең күңелендә бу уй.
Бу уй һәммәсенең телендә.
Кабатлана калса зур корылык,
Тарих тапмас безнең көлне дә.

Янып көлләр булып сибелимме...
Җаным атыйммы әллә галәмгә?
Баскын белсен,
барыбер төшәчәкмен
Корым булып гадел каләмгә!

Татар җаны бүген галәмдә шул,
Татар җаны яшел әләмдә...
Татар җаны бүген чын тарихны
Гадел язар олуг каләмдә.



## *Акылыбызга килик!*

**1**

Яз агачы яфрак түккән сыман
Татарстан түкте егетләрен.
Бүген килеп кабат күралмабыз
Без аларның инде бик күпләрен.

Тамырында талпынып ла калган
Агач кебек бүген анакайлар.
Кош очалмас җиргә озатылган
Газиздән дә газиз балакайлар...

**2**

...Без — аналар илсез, дәүләтсезме?
Ватансызмы әллә уллары?
Дәүләтенә түгел, бер Ходага
Ярдәм сорап сузган кулларын.

Бу ирләрнең юкмы иманасы?
Юкмы иле? Юкмы Ватаны?
Булса, нигә күтеп тора алар
Табутларның гына кайтканын?

Кургаш табут, аннан сезгә кабык.
Ил ирләре, дәшми тормагыз!
Аналарның сабырлыгы сынды —
Сабырлыктан туплар корабыз.

Тормыш бирер, яшәтергә килгән
Ана җанын утка салдылар.
Киләчәгем диеп баккан улын,
Өметләрен тартып алдылар...

## 3

Без җәядәй киерелдек бүген,
Бәйсезлекне генә саклар өчен.
Дошманына җаны белән ата
Чечен киләчәген яклар өчен.

Малыбызга хуҗа булып алды,
Җаныбызга Рәсәй хуҗа түгел.
Мал талаган җан таламас диеп,
Әйтә ала икән кем соң бүген?

Ил ирләре, нишләп дәшмисез сез? —
Татар милләтенең бармы юлы?
Бармы теле, бармы җире — җыры?
Бармы калкан булып басар улы?

Без — аналар, бездә татарларның
Киләчәккә яраласы каны!
Без — аналар, татар милләтенең
Саклап йөртүчеләр моңлы җанын.

Без илбасар түгел, илле халык.
Кавказ халыклары — бездә хаклык!
Тарих җавап алыр синнән, мөртәт,
Тәмуг төбеннән дә тартып алып.

Рәсәй, тукта, һушыңа кил, чиген!
Сиңа дәшә дөнья халкы бүген!
Татарстан дәшә, Идел-Урал!
Тукта, Рәсәй, тукта, кире чиген!!!

Акылыбызга килик, килик, әйдә! —
Халыкларны тотмыйк,
тотмыйк бәйдә!

# *Мәйданнарда ачыла җан*

Әй, күңелләрнең чишелгән,
очынган мизгелләре!
Кояшы сүнгән күзләрнең
очкынланган көннәре!

Ялтырап кояш чыгуы болытлар арасыннан,
Җаннарның аралануы ямансу ярасыннан!

Бар дөньяга түгелүе кояшлы сагышларның,
Кушылуы бер-беренә
җан-канат кагышларның!

Тургайларның бер мизгелгә тынып,
тыңлап торуы...
Сабан туең гөрли илдә, ата-баба ыруы!

Телдән телгә, илдән илгә моң ага, сагыш ага,
Моң-сагыш, кайгы-хәсрәтне
«кояшлы» җырлар «чага»!

Мәйданнарга чыга тальян,
менә ни чишә җанны!
Сөлге тоткан көрәшчеләр алачак
бүген данны!

Моң-шатлык кушып чигелгән сөлгеләр
каралмыйлар.
Яңгырлар коеп яуса да,
мәйданнар таралмыйлар!

Ява яңгыр килә-китә,
жырлар чыланмый икән!
Халык чынлап бәйрәм итә,
юри кыланмый икән!

Чүлмәкләрне чәлпәрәмә коеп төшерә колга...
Баганадагы әтәчне малай төшергән кулга!

Парлап бәйләнгән аяклар
тәки ярашып бара,—
Нәрсә ул парлап йөгерү,
син капчык киеп кара:

Богауларның, капчыкларның
ни икәнен белгәнгә,
Җиңгәннәргә мәртәбә зур,
асыл бүләк — җиңгәнгә!

Мәйдан әйләнеп узыша
елтыр күзле малайлар!
Киләчәккә — фатиха! — дип,
куаныша агайлар!

Колгадагы сөлгеләрнең
кызлар чиккәне матур,
Бары мәхәббәт алдында тезләнгән егет батыр!

Әй, күңелләрнең күкләргә менеп
күкрәгән чагы!
Сабантуйдан олы бәйрәм бармы соң
җирдә тагы!

## *Татар туктальшы*

Тукталдым да тынып калдым,—
Бу нинди мизгел, ниткән?
Нидән аяклар атламый?
Ник кулдан эшем киткән?

Юл гына түгел, бу көндә
Киселә хәтта уйлар.
Кәләш туй күлмәген кигәч,
Туктап калганмы туйлар?

Көзге яфраклар да гүя
Җиргә төшәлми тора.
Исәр җилләрне дә хәтта
Кемнәрдер кире бора.

Җил борылыр диләр микән?
Җир борылыр диләрме?
Үз җайлары өчен генә
Эшләтмәкче миләрне...

Кискәлиләр, кискәлиләр,
Бәгырьләр парә-парә.
Киселгәндә ачу-аю, —
Урманга кереп бара...

Тукталдым да тыңлап торам:
Тамырлар сөйләшә бит;
Сак булыгыз, бүген шайтан
Өммәтен өләшә, дип...

Шайтан өммәте бер көнлек,—
Көнлекче була күрмик!

Шайтан мөлкәтен саклаучы
Милекче була күрмик!

Тамырларны саклар өчен
Хатын-кызны зурлагыз!
Туган телдә мәхәббәткә
Мәңгелек җыр җырлагыз!

Кулы — камыр, ана — тамыр.
Ир-ат — сакчы тамырга!
Шулай булса гына мөмкин
Киләчәккә барырга.

Туктадым да тыңлап торам,—
Җан белән сөйләшә җан:
Тамырыннан өзелгәнгә
Мәңгелеккә өзелә сан.

Кискәлиләр көнлек җанны,
Милләтеннән киселгәнне,
Теле, җире, милләтеннән
Аерылган мөселманны.

Кизәнәләр, кисәм диеп,
Инде милләт җанына.
Җан сорап йөри кемнәрдер,
Саткан да шайтанына...

## *Тукайга дәшү*

Нихәл, Тукай?
Җанда нинди гамьнәр?
Таш сыныңны сыгып аумыйсыңмы?
Җан җылысы эзләп сиңа «килдем»,
Эшләр кая бара, аңлыйсыңмы?

Дөнья кызу!
Җан әрнүдән тора,
Таш булсаң да елый алмыйсыңмы?
Ташлар булып ташлар ыңгыраша,—
Дөнья кая бара, аңлыйсыңмы?

Анда ташлар,
Монда башлар ава.
Коллык богауларын таныйсыңмы?
Җан кадәрле җанны кол итәргә
Инквизиция бара, аңлыйсыңмы?

Анда таулар,
Монда олуг Идел
Аягүрә баскан, тоясыңмы?
Салым түләгәч тик яктыртырга
Фәрман чыгарылган кояшыңа.

Агач төбе,
Ат аунаган төге,—
Һәммәсенә салым салынган бит.
Милләттән җан, мөлкәте һәм аңы,
Җирнең мае сыгып алынган бит.

Нихәл, Тукай?
Монда шундый хәлләр.
Таш сыныңа килдем җылы эзләп.
Җаннарда таш, таштай ауный башлар,
Киселәләр алар йөзләп-йөзләп...

Нихәл, нихәл,
Тукай атлы әрнү?
Мин Нәҗибә атлы җан ярасы...
Тау ватканчы әле кирәк иде
Тузаннарга тауга табынасы...

Нихәл, тарих —
Олуг Тукай атлы?
Монда тузан сулышларны каплый.
Җаннарда да хәзер тау ярасы,
Тауларда да икән җан ярасы,—
Бер Аллага калды ялварасы...

Дәш, Таш Тукай!
Җанда нинди хәлләр?
Таш сыныңны орып аумыйсыңмы?
Җаннар хәзер таштай катып калды,—
Таш Тукаем, безне аңлыйсыңмы?
Күз яшьләрен безнең таныйсыңмы?

## *Рәхмәт, якташ!*

*Марат Кәримгә*

Саумы, якташ!
Саумы туган якның
Безгә яшәү көче биргәне?
Саумы, Агыйделнең сылулары
Тик минеке диеп йөргәне?

Саумы, саумы,
Җаны даулы диңгез!
Төпкәйләре тирән ятканы?
Саумы, вулкан яшерелгән Урал —
Җаннан асыл ташлар атканы!

Саумы, җаның,
Җанга сыйган ягың?
Саумы җаның сыга алган тел?
Өмет анда нинди хәлләрдә,
Җаннар бәргәләнгән мәлләрдә?

Сорау арты
Сорау гына димә,—
Хәл белүем шундый, якташым!
Җан вулканың аткан шигырьләрдән
Җыеп йөрдем кара-ак ташын.

Дөнья кебек
Төсле икән җаның.
Төсле, хисле, көчле, уй тулы.
Язмыш сиңа бүләк иткән икән
Иксез-чиксез генә уй юлы.

Ә уйларны
Кисә алмый дөнья,
Кисә алмый хаким кайчысы.
Уйлар юлы — бакый, кисүченең
Бакыйлыкка бара кайсысы?..

Саумы, якташ?
Саумы, шигъри юлың,
Мәңгелеккә илтә торганы?
Туган җирең, туган телең саумы? —
Җанны бакый итә торганы?

Авырлыкта
Сабырлыклар телим
Марат Кәрим дигән акынга.
Җаным синең җанга бәрелә дә
Әверелә шигырь-ялкынга.

Шагыйрьләрнең җаны фани түгел,
Бакыйлыкны тану хакына!

## *Тукай кабат туар...*

Мин шатлыктан күккә ашар идем,
Очкан кошны тотып кочар идем,
Күңелләрнең садә кылларында
Бәхет көен табып уйнар идем...

Бәхет көе шундый булыр иде,
Бәхетеннән ярлар тулыр иде.
Җырлап торыр иде бар мәйдан
Һәм таң калыр иде: моң кайдан?

Мәйдан көләр, мәйдан биер иде,
Әй очыныр иде шатлыктан!
Хәтта таш сынына Тукайның
Җан өрелер иде хаклыктан.

Мин шатлыктан иңрәп үләр идем,
Һәр бөҗәкне тотып үбәр идем.
Шүрәлесе кытыклаган кеби
Шатлыгыннан Тукай көләр иде...

Тик әлегә Тукай таш сын гына,
Юк, биеми мәйдан әлегә.
Тик җаннары һаман зынҗырда,
Мәйданнарда сирәк чын җыр да.

Ул чын булса, әйе, елый гына.
Ул чын булса, иңри, игәлә.
«Коллык богауларын өзәргә!» — дип,
Бакый җаннар фәрман биргәнгә.

Ул чын булса, җирнең үзе кебек
Ыңгыраша табан астында.
Чечен каны тама аңардан —
Иске яралары яңарган...

Ул чын булса, аның таләбе бер:
Дәүләт кирәк җирдә яшәргә!
Дәүләт кирәк, дәүләт теле кирәк
Чын шатлыклар белән яшьнәргә!

Ә әлегә күккә ашар өчен
Канат—бәйле, богау — аякта.
Богау — телдә, богау — кулларда.
Һәм Чечнядә әле уллар да...

Ә әлегә Тукай катып калган,
Җанында таш ничек эресен?!
Безнең хыял әгәр чынга ашса,
Җан иңәчәк аңа, күрерсең...

Менә кайчан Тукай кабат туар.
«Христос кына воскрес», димәгез.
Шагыйрь юкса ул очарга тиеш,
Кошлар гына оча, димәгез!..

Без әлегә хыялларны кочып,
Канап торган җиргә иңәбез...
Бу сүзләрдә тамчы ялган да юк,
Шагыйранә ялган димәгез...

## *Искә алу көнендә уйлану*

Сине искә алу көне, диләр,
Истән чыккан чагың бармыни?
Нигә шулай иртә китеп бардың,
Безнең дөнья шулай тармыни?

Ташкыннарның гомере язда, беләм,
Ярларга да сыймый җырларың.
Әллә ничек кенә кысыла да
Тарая шул яры чорларның...

Тик ярларны кысып түгеп булмый
Халык моңы дигән назларны.
Кырык катламнарны үтеп чыгып,
Исемнәре кайтты азларның.

Яшеннәрне яшереп буламыни? —
Син китмәдең безнең күңелдән.
Син халкымның җаны тулып ташып,
Изге моңы булып түгелгән...

Сине бүген искә алу көне —
Шундый йола безнең халыкта.
Ничек онытсыннар, күңелләрнең
Олуг өметедәй калык та.

Синең бары җырлап бу дөньядан
Китеп барган көнең, Тукайҗан!
Чишмә җырлап, кеше елап туа,
Җырлап киткән үлми һичкайчан!

## *И-и, Тукайҗан...*

И-и, туганнар!
Каршыгызга чыктым,
Басып торам:
Җаным тагын
Сезнең җанга орам,—
Ни хәл генә итим,
Нишлим лә?
Тагы иренемне
Тешлим лә...

Хак дөресен
Әгәр әйтә калсам,
Җан илемнән мине
Куарлармы?
Кумасалар,
Бәлки, кумаслар да...
Әмма
Мыштым гына
Буарлармы?!

И-и, Тукайҗан!
Мин каршыңа чыктым.
Басып торам:
Җаным тагы
Моң-сыныңа орам —
Сине сөйгән халкың
Бүген дә
Басып тора
Ишек төбендә...

Бәй-й...
Син үзең дә
Әллә кайда түгел,

Басып торасың ич
Бүген дә
Зу-у-р мәйданның
Уртасында түгел,
Халык йөрмәс
Ишек төбендә.

Моннан үтеп-сүтеп
Йөрүчеләр
Борылып та сиңа
Карамыйлар.
Мәйданнарда, —
Анда башка кавем,
Сине тотып тора
«Ярамыйлар»...

Бәй-й-й...
Бүген дә
«Заман — көчленеке!»
Халык уе
Бары уенчыкмы?
Синең исемең белән
Уйнаргамы? —
Лауреат, дигән
Уен чыкты...

Уен түгел
Халык уе иде,
Күрәсеңме,
Нинди заман килде?
Дәүләтсез һәм
Телсез калган халык
Үзе күптән
Кәмит уйный инде.

Тик белсеннәр,
Бу янавым түгел:

Кәмит бетте —
Кәмит Ia finist!
Туры Тукай булсам,
Әйтер идем...
Әйтә алмыйм...
Әйтәм: зашибись:
Халык уйларын да
Уен итеп,
Кидергәнгә чылбыр
Уйларга.
Якын килә алмаячак
Тиздән
Түрә-мүрә
Сабан туйларга...

Халык уен,
Хәтта сабан туен
Әверелдереп
Рәсми бәлагә,
Имчәк урынына
Әллә нәрсә
Каптыралар
Безнең балага...

Бу янавым түгел,
Тик әлегә,
Бу ямавым
Җаным ярасын...
Исләренә
Бер төшерим дидем:
Уен беткәч,
Хәтта түрәнең дә
Безнең белән
Бергә барасын!
Башка юл юк —
Бармый карасын!..

## *Егылмасын, югалмасын дисәң...*

Юллар өзелгән чак була
Җәяүлегә, атлыга.
Еллар өзелгән чак була
Туры сүзле, хаклыга.

Телдән телгә генә күчеп
Яңгырый ул чак чын сүз.
Өзелә үзәк, киселә бәгырь —
Дәшә генә күрмә, түз!

Моңнар өзелеп калмасын,
Моңнар җаннан агыла.
Туган телең тамырына
Балта-пычак кагыла.

Үзең белән бу дөньяга
Бергә туган телеңне
Туфрагыңа ялантәпи
Баскан газиз җиреңне
Үзеңнеке түгел диеп
Исбат итәләр икән,
Ул бәндә үз иманыннан
Әллә кайчан ук киткән.

Өзелмәсен дисәң юллар,
Өзелмәсен дисәң уйлар,
Егылмасын дисәң ирләр,
Югалмасын дисәң илләр,
Яклау кирәк туган телне,
Аклау кирәк туган телне.
Туган телне, туган җирне
Туган телдә, туган җирдә
Яңгыраган изге җырны.

# *Ә күк эзли*

*Фәннур Сафин*
*истәлегенә*

«Урман ничек шаулар?» —
дигән идең.
Урман шаулый... авыр...
Яфраклары ничек шаулаганын
ишетерме тамыр?

«Ишелмәсме таулар?» —
дигән идең.
Ишеләләр таулар.
Син киткәннән бирле афәт илдә,
тынып тормый даулар.

Урман «Фәннурсызмын» —
дип шауламый,
«Бер былбылым,— ди,— ким».
Таулар да бит бер бөркетен җуйса,
моңаерга мөмкин.

Ә күк эзли ике зәңгәр күзне —
синең күзләреңне.
Тауда үскән агач тамырлары
илтсен сүзләремне:
«Урманнары синең җырны җырлый,
әнә — тыңлый таулар.
Җырларга да туплар атып тора,
җырлар исән-саулар!»

## *Ә чынлыкта...*

*Халисәгә*

Туган җирләрдә яшисең,
Ничек хәлләр Халисә?
Ярый, диеп елмаясың,
Ә чынлыкта хәл исә
Елмаю түгел, еларлык,
Сыгылырлык, сынарлык.
Ә барыбер елмаясың:
«Була инде, була дисең,
Ачуланасың кемгә?»
Яңа сәясәт, яңа тел
«Бүләк» итәләр көн дә.
Бүләккә алынган иман,
Бүләк ителгән телең,—
Кая таба алып барыр,
Әгәр дә алсаң, белмим.
Шулайлар әйтер идең лә,
Әгәр зарлана белсәң.
Елмаясың да йөрисең,
Син Казаннарга килсәң.
Ярый, дисең, елмаясың,—
Ул хәлләрдән көлмичә.
Яшәп кенә булмый икән
Казаннарга килмичә.
Син килдең, яз белән кыш
Тарткалашкан көннәрдер.
Көннәр җылынмасын диеп,
Фәрман яза кемнәрдер...

## *Фикерлене күтәрә алсак...*

Рәсәй тәхетенә иблис менде,
Нәни тәхетләрдә варислары.
Җимерүләрен сизмәсеннәр диеп,
Бишек җыры көйләү бар эшләре.

Җаннан чыккан җанга иңгәнлеген
Аңлап алды алар, аңладылар.
Әмма ашыгалар, тизлекләрен
Берничек тә көйли алмадылар.

Алар җыры халык моңы түгел,
Алар җыры бары такмак кына.
Сүзен язып, җырын җырлап йөри
Шуны аңламаган ахмак кына.

Ашыгулар шайтан шөгыле шул,
Шайтан чирен кеше йоктырган.
Эш кырмыйча, бәхет табам диеп,
Шайтан сүзен тоткан оттырган.

Бүген бар да сорый кыскалыкны,—
Кыска сүз, уй, кыска итәкләр.
Кыса алсаң, ачтан үлмисең дип,
Киңәш бирә миңа тинтәкләр.

Ә мин кыска түгел, кышка язам,
Ап-ак карда калсын җан эзем.
Ташкын булып ак син океаннарга,
Болыт булып күккә мен, сүзем!

Яу, коеп та, ләйсән булып та яу —
Һушларына китер халкымны!

Ашыкмаска өйрәт, ныклап өйрәт,—
Тиеш җиргә салсын ялкынны!

Тәхетләрне нигә яндыралар? —
Ах, туйдырды инде җан сораулар!
Тукайларны тартып алды алар,
Бүген ифрат авыр җан асраулар.

Ә чын шагыйрь халык көен көйли,
Һәм нәкъ менә шуны иблис сөйми.
Фикерлене күккә күтәрә алсак,
Хак Аллага илче җибәрер чак.

Әйтсен, халык көен көйләгәнгә
Яшьли Тукай җаны кыелганын.
Иблис менгәч, Рәсәй тәхетенә,
Халык сүзе тәмам тыелганын.

Галиҗәнап сүзнең гаделлеккә
Иң зур кораллыгын танымыйлар.
Шайтан суын, наркотигын эчеп,
Исергәннәр инде айнымыйлар.

Әйтсен: туплар гына сөйли хәзер,
Ә шагыйрьләр — аяк астында.
Бер күз салсын әле безгә Алла,
Күк капусын гына ачсын да.

Ходай тәхетендә иблис бүген,
Шуңа тыныч түгел дөнья күге.

# III

*Тарсынма бер дә, китәрмен:*
*Җен, иблистән дә битәрмен,*
*Үз белгәнемне итәрмен, –*
*Ки әгъли – гъәршә ашкындым!..*
*Кусагыз да, һич уфтанмам,*
*Язуымнан да тукталмам;*
*Котылмассыз барыбер сез,–*
*Әле болай гына калмам.*

Габделҗәббар Кандалый
(1797 — 1860)



## *Әй бу күтәрелүләр...*

Күтәрәләр өстән,
Күтәрәләр астан.
Күтәртәләр өстән
Килмәгәнгә көчтән
Күтәрелү астан.

Күтәрелә астан
Үлә язып ачтан.
Күтәрәләр өстән,
Авыр түгел һич тә.
Лифтә белән менү
Таләп итми көч тә.

Өстә йөзә күбек,
Өстә йөзә чүбек.
Төшәлмиләр аска,—
Тормыш дулкынында
Була алмый башка.
Бик күбәйде хәзер
Бик «акыллы» башлар.

Төптә ята ташлар,
Төптә уйлы башлар...
...Яңа заман үзен
Өр-яңадан башлар.

# *Җан халәте*

Җан үлми —
чыгып китә.
Һәм гомер...
җансыз үтә.

Җан керә дә
кеше туа дөньяга.
Җансызлар җансыз
туа дип уйлама.

Тик җан бер чак
әйтмәк була барлыгын.
Олуг җанга
бу бәдәннең тарлыгын.

Сорап-сорап
ала алмый мәйданны.
Күрүче юк
тәндә йөрәк янганны.

Күтәрмәкче,
күрсәтмәкче җан үзен.
Тыйнаксыз булма, җаным, дип
әйт сүзең.

Җан зинданда шул,
танымасалар аны,
Чыгып качар
җансызның җансыз җаны.

Дәвам итәр өчен
яшәүне җирдә
җан эзлидер
үзенә лаек гәүдә.

Әй җан яна
Күрегез дип, әй балкый!
Әйтәләр: бу —
башка планета халкы.
Калсак җанны
күзәтергә тик читтән,
Җирне дә җаны
ташлап китмәс микән?

Әйе, җан
Чыгып кына китә.
Йа Хода,
бәлки, без җир җанлы
соңгы планета?!

## *Фанилык кына җаннарга!*

Җан ачуым белән чыктым,
Каршы килдем карага.
Ялагайлар керделәр дә
Тоз сиптеләр ярага.

Бәргәләндем дә ярсыдым,
Чыктым ярларымнан да.
Башкаларга ачы булды
Минем зарларымнан да.

Кара кара булып калды,
Акларым да тапланды.
Шөкер, бер Алла кулында,—
Ул җанымны саклады.

Аллага тел тидерәләр:
Бир, диләр, аның җанын!
Шуның җанын алып булмый,
Кыеп булса да санын...

Җан мәңгелек икәнлеген
Онытты шагыйрьләр дә...
Хәмергә баткан җаннармы? —
Юк, түгел шаһ ирләрдә.

Мин сезгә башка кычкырмам,
Фанилык кына җаннар!
Бакыйлыкта яшәү башка,
Сезсез атачак таңнар!

Фанилыктагы шикелле
Исереп йөрмәс кояш!
Язмышларын сезгә бәйләп,
Хатыннар кан–яшь коймас.

Кояш та, ае да аек —
Алар бакый җисемнәр!
Фанилык кына җаннардан
Калмас анда исемнәр.

Мин сезгә башка сүз катмам,
Фанилык мескен җаннар!
..........................................
Бакыйлыкка кем узардан
Чабышкан була саннар...

## *Бер биедем туйганчы*

Нефтекама бию ансамбле
чыгышын караганнан соң.

Сәхнәдә яшьләр бииләр,—
Сәхнә — унсигез яшьтә.
Ә миңа ничәдер дисез,—
Яшемне әйтмәгәч тә...

Болын күбәләкләренең
Җилкенеп очуыннан,
Ут күзле яшь егетләрнең
Кызларны кочуыннан
Көнләшүенә чыдамый
Йөрәк чыкты читлектән,
Никләр шушы яшькә кадәр
Ул читлектә интеккән?!

Ярсып, очып, йөгереп чыкты
Каршысына егетнең...
Әйтмәгәч тә, беләсезме
Кем ул егет, кем ул, кем?
Уналты яшьлек Әхмәр ул,—
Оялчан, үзе кыю...
Хыялым ирекккә чыкты,—
Юк аны башка тыю...
Әгәр дә кочакламаса,
Кочаклап үбәм үзем.
Ах, ни булды соң йөрәккә? —
Әллә ялгыша күзем...
Оялып кызарынды да
Пәрдә артына качты.
Әхмәр оныгы алдында
Гомерлек серне ачты.

Йөрәкне читлек эченә
Кайтарып булмый ансы...
Рәхмәт, яшьлек сәхнәсенә,—
Бер биедем туйганчы!

## *Булмаса да «Була» — ул...*

Шаярган, көлгән булам...
Күңелләр тулган була...

Булмый икән талант,
Алып булмый талап.
Булмаса да талант,
Куела шундый таләп:
«Шуны күтәрергә!
Мактап җиппәрергә!
Югары бүләкне
Нәкъ аңа бирергә!»

Һәй язалар гына
Түрәләргә ярап.
Ничек күрмәгәнбез
Була яздык харап!

Халык шагыйрьләре
Сүз башлары яза.
Җаннарында яшерен
Ачу уты яна.

Алар белә, данны
Алып була... ялап.
Талантлар утыра
Җан ярасын ямап...

# *Ы-ы-ы... дөнья көйсез*

Бар да талпына бүген,—
Күккә менәсе бар да.
Чуртан бахыр бәргәләнә,
Судан ташланган ярга.

Юкса менәсе иткәндер
Айлы күккә чуртан да.
Әмма барып чыкмаган шул
Бу уеннан чуртым да.

Бар да талпына күккә.
Күге түзәрме күпкә?
Ачылган авызлардан тик
Күренә алсу үпкә.

Төзәтәләр: «Кара,— дип,
Үпкәләрдә яра бит.
Айга карап ялварулар
Инде соңгы чара бит».

Ах, дөнья... нигә һаман
Ай ялгыз, өйләнмәгән?
Димәк, әле галәмдә дә
Дөньялар көйләнмәгән...



## *Туган көндә «улу»*

Көзен җиргә яфрак сибелә дә,
Сары моңга бата дөньялык.
Мизгелләргә кереп чумып шулай,
Көзләр җитте, диеп уйладык.

Уйлар булып юлга карлар төште,
Алда — кузгалмаган ташулар.
Әле алда, мин бәхетле, диеп
Сөенечтән күккә ашулар.

Бөре булып язда ачыласы,
Түгеләсе сөю хисеннән
Хыялларны пар канатлар итеп
Кайтасы бар яшьлек киченә.

Әле сагынулардан саргаюлар,
Әле сагышлардан сулулар.
Ялгышканмын, әле мин яшь, диеп
Кабат мәхәббәттән тулулар.

Гомер көзгесенә бага-бага
Таң каласы үткән гомергә.
Җан җылыңны биреп, өрә-өрә
Ут саласы сүнгән күмергә.

Яңа учакларны кабызыр өчен,
Җанда саклау соңгы очкынны,—
Көздән язга кереп булмый, диеп
Ышандырып булмый һичкемне...

Алда әле, алда без белмәгән
Ләззәтләре яшәү мәненең.
Әле алда без беләсе сере,
Без ачасы сере мәңгенең...

Әле алда без тыңлыйсы язлар
Колакларны куеп ташкынга.
Җан — мәңгелек,
                    юкка хафаланма
Бу гәүдәне туфрак басканга.

Җанга иңгән сары көзләр кала,
Кала җанда ярсу ташулар.
Кала яшел моңга чумган җәе,
Мәхәббәттән күккә ашулар...

Соң шуларны үтереп буламыни?!
Алып китеп булмый кабергә!
Мин үлмимен, бары әйтә алам:
Сау булыгыз, дуслар, хәзергә!

## *Дөньясы көлеп тора*

Әй, яз җиткәч, агачларда
Бөреләр борын төрткәч,
Ни дип явасың син, әй кар,
Төшүгә эреп беткәч?

Җилгә ятып, иләс-миләс
Очып йөргән кар кызы
Телгә килде, әйтте миңа:
«Мин — дөньяның әрсезе.
Кышкы салкыннар, ахры,
Хисләрне тота бәйдә.
Кар булып яшисем килә
Минем ямь-яшел җәйдә».

Дөньясы көлеп тора:
Әйттем:
«Яшәп кара, дип, әйдә».

## *Тәүбә... тәүбә...*

Уеныннан туйдым муенымнан,
Кая китте ихлас сүз сөйләү.
Хәзер инде бөтен сөйләүләре
Берәүләрнең көен тик көйләү.

Күз алдында кояш яктысында
Күз дә йоммый ялган сөйләнә.
Язмыш җебен кемгә тоттырганбыз,
Сукырлыклар шулай түләнә.

Кояшы да, ае да юк аңа.
Ходасы да гүя булмаган.
Иблис алган язмыш буйлап бара,
Күпләр аны күптән аңлаган.

Дилбегәне тартып алып булмый,
Кара йөзен ничек ачсын ул.
Үз-үзеннән әллә кайчан туйган,
Үз-үзеннән ничек качсын ул?

И Ходам, дип, авыз чайкаулардан
Иман тулмый бәндә җанына.
Иблис «язган» язмыш шундый инде,
Ул каера үзе ягына.

Көтмәгәндә сүзләр киселәләр:
Кәмит бетте, беркем сүз әйтми.
Әйтә калса аны хакыйкатьне
Бүген өенә үк ул кайтмый.

Уеныннан туйдым муенымнан.
Ихлас сүзгә сусап сусала!
Ошбу ялганнарны күтәрә алмый
Һуштан язган Ходай, булса да...

# *Ә без һаман таш җыябыз*

«Люди взамнившие себя богами, не могут приносить счастье другим».

*(Телеэкраннан)*

Син үзеңне юкка гына
Пәйгамбәр дип аһ ордың.
Иблиснең табан астында
Тик олтан булып тордың.

Алладан башка Алла юк.
Кешелегең оныттың.
Нигезеңә таш булырлык
Башкаларны он иттең.

Инде син һич аптырама
Ник язмыш ыргыта дип.
Мин дә юкса адәмдер лә,
Бәргәч бик авырта бит.

Кулыма ташны алам да
Карап торам аптырап.
Кемнеңдер башы күз кебек
Карап тора җан сорап.

Ә без һаман таш җыябыз.
Күпмедер җыясыбыз.
Күзне төртеп чыгарбыз,
Аннары каш ясыйбыз.
.......... юкка гына...

## *Тама әле...*

Бу журнал бик якты
Шәмдәй яна иде.
Битләренә очкын-очкын
Шигырь тама иде...

Көтмәгәндә якынлашты
Ахырына гасыр.
Уй төште: гасыр капкасын
Кемнәр килеп ачыр.

Уйлаштылар:
Киләсе гасырга
Монсын алсак, ярар!
Анысын алсак — ярар!
Ә талантлылары
Үз-үзләрен карар.

Язалмаганнарны
Танымый ул тарих.
Безнең кулда журнал
Һәм дә влач бар ич.

Һәм тезделәр алар
Исемлекне шулай:
Безгә яшәү өчен
Менә шулай кулай:
Туфан таныганны
Кире кагып булмый.
Соңлап килгәннәрне
Сафка алып тормыйк.
Ирләр булсын хаким,
Хатын-кызлар — ятим.

(Һәм уйласын тарих
Бар дип Ренат Харис).
Тагын бер сүз әйтим:
Борчылма хатын-кыз! —
Тукай да бит ятим...

Тарих туктап калган,—
Ачылмый бит капка,—
Язылганга ялган
Кара белән акка.

Шаклар катып торам
Хакыйкать юклыкка.
Тик хакыйкать бар ул,
Ул әле тик читтә.
Ачык инде капка,
Ә тарих үз сүзен
Әйтәчәк ничек тә.

Җибәрәчәк тарих
Ялганнарны куып.
Һәм бәя куячак,
Булган дип буш куык.

Ә шулай да журнал
Шәмдәй яна әле.
Битләренә шактый
Шигырь тама әле.



## *Сату*

— Ник бәрәңгеңне сатасың?
— Ашап булмый, агулы...
*(Базарда сөйләшүдән)*

Апа бәрәңге сатты,
Бетте — капчыгын какты.
Тузанны сатып булмый,
Узганга кайтып булмый.

Апа вөҗданын сатты,
Әмма какмады җанын.
Чыкмаган җанда өмет,
Буш гәүдә тора көлеп.

Бәрәңге агулы иде,
Сатты, вөҗдан булмагач.
Өч тиенлек фани җанын
Мәңгелек дип уйлагач...

## *Ничек туктатасың?*

*(Бер ханым авызыннан)*

Мин бер уйсыз китеп бара идем,
Үткенче җил үпте битемне.
Җилләр китте, җилләр югалды ул,—
Мин нәни кыз таптым ятимне.

Әй сакладым аны җил-давылдан:
Үткенче җил генә үпмәсен.
Җил кызлары табып ятимемнең
Гомеркәе зая үтмәсен.

Ишетми дә кызым, җил иркенә
Толымнарыңны, дим, таратма!
Кирәк түгел, җыйчы итәкләрең,
Үткән-сүткәннәрне каратма!

Җилләр исте, яфракларны кисте,
Күпме яфрак сары коелды.
Сагышларны җыеп күккә чөйсәң,
Кояш булыр кебек тоелды.

Тик яфраклар җиргә ятып калды
Өзелгән җыр, тамган сагыштай.
Кызым елый: бәби табам, әнкәй,
Мин сөйгәнем белән кавышмый...

Җилләр исә, һаман җанны кисә,
Ничек туктатасың — җил бит ул!
Җил тудырган хисләр сөю түгел,—
Күзгә, йөзгә сипкән көл бит ул...

## *Мәче белән шагыйрь*

Мәче малаен кочаклап,
Мин әле җыр язамын.
Мәче шуны укый-укый
Әйтеп тора азанын:
«Син җырыңны яз,— ди ул,—
Табигатьтә яз,— ди ул,—
Мин бит Тукай моңнарыннан
Өзелеп төшкән саз»,— ди ул.

Ышанмыйча хәлем юк,—
Соң тарихтан дәлил юк.
Мәче мырлый, шагыйрь җырлый,—
Шунсыз дөнья яме юк.

# *Тәртип...*

Бар дөньямда тәртип:
өстәл җыйган,
Юган-җәйгән килеш урын-җир.
Табак-савыты да шалтырамый,—
Күптәннән юк инде өйдә ир.
Атна буе сыңар тустаганнан
Юып тормый гына чәй эчәм.
Салкын түшәгемне ачуланып,
Атып бәрдем әле мин кичә.

Бар дөньямда әллә нинди тәртип,—
Бар да сыңар-сыңар тезелгән.
Сумка бавын тегәр өчен менә
Без эзлимен, бавы өзелгән.
Буйсынмый без, шундый авырттырып
Чәнчеп алды бармак битенә,
Энә генә түгел икән бу без,—
Атып бәрдем дөнья читенә.

Әткәй булса, әйтер иде бер сүз...
Ә мин киттем остаханәгә.
Акчаң булса, тегеп бирәләр ич,
Ник кадалып торам энәгә?
Һәм эштән соң өйгә кайтырга дип,
Тукталышка килеп туктадым.
Юылмаган сыңар тустаганым
Күз алдыма чыгып буталды.

Өйгә кайтмыйм, анда шундый тәртип...
Ә кафеда чиста тустаган.
Ә кафеда әллә ничә кеше
Кичке ашка диеп туктаган.
Никләр эчтем салкын кофеларын,
Кайтып киттем тагы шул өйгә.

Ә өемдә тәртип бозылмаган,—
Ялгызлыгым елый бер көйгә...

Андый елак мин үзем дә бар дип,
Ялгызлыкны тотып селектем.
Хөрмәтова кассетасын куеп,
Өй селкетеп биеп тә киттем...
Пешерергә куйдым итле аш,
Әллә күз чыккан да беткән баш?
Майлы коймак чыжлый табада һәм...
Сатлык ай... төпсез һавадан
Тәрәзәмә килеп капланды...

Ап-ак эскәтердә ай ята...
Коймагым — таш, тора тамакта.
Хөрмәтова кассетасы сүнде.
Вакытта да шулкадәрле тәртип,—
Берни булмагандай таң ата...

## *«Дәүләтчә» уйлау*

Ачлар, урамга чыкмагыз! —
Өегез дә юкмыни?
Өшемисез, зәмһәрир бит,
Җаныгызда утмыни?

Әфарин! Нинди могҗиза! —
Без ясаган феномен!
Мин нәфис шул, тун эчендә
Тук килеш тә туңамын.

Кәнизәкләр кочагына
Ашыгамын шуңа мин.
Ә машинам «Шевроле»,—
Тота алмый Шүрәле...

# *Куышсыз куян...*

*(Аңлатма язуы)*

Кесәдә — сукыр тиен,
Өстемдә соңгы кием.
Әле, шөкер, җан исән,
Илне иңләп, җил исә.
Җил безнең кесәләрдә ул,
Бик җилле безнең кием.
Тәки таба алмадык без
Бу сәер илнең көен.
Ул кушканча сөйләштек гел,
Тамагын да туйдырдык.
Җирен чәчеп-урып бирдек,
Куышыбызга сыйдырдык.
Нинди хәлләргә калдык бит,
Уян, туганкай, уйлан —
Без бит куышына төлке
Иялэшкән бер куян!
Әкиятнең ахыры матур...
Ә безне ниләр көтә?
Чүплек башында казынып,
Эт-мәчегә өйдәш булып,
Кемнәр бүген көн итә...
Төлке күңелен күрә-күрә
Әллә терәлдек сазга?
Чигенүләрнең чигендә
Әверелдекме бомжга...
Баш ватам: бу сәер илнең
Җаен табарга каян?
Шушында нокта куям.
Имзам — куышсыз Куян.

## *Мәсьәлә*

*(Кәҗә елын каршылаганда)*

«Мә-ә-ә»,—
ди кәҗә белән сарык,—
Ни бирәләр, барып карыйк.
«Мә» дигәнне ишеткән бар,
Ышаналмый тора татар.

«Мә,— ди кәҗә,— мики-ки-ки,
Капчыктагы бүре башы
бит унике...»
Аптырашта тора сарык...
Тәмам тинтерәгән халык...

«Мә» дигәне мәзәк кенә,
Бирә иде...
электән дә эзләп кенә.
Инде хәзер гүпче буш кул.
Болай булса, хәлләр мөшкел...

Димәк, кәҗә: «Мәсьәлә,— ди,—
Ышанулар — вәссәлам!» — ди.

## *Әллә төш, әллә өн...*

Ялгыш кына мин чит илгә
Чыкканмын, имеш.
Ул илнең эсселегенә
чыдамыйм, имеш.

Автобус тукталган мәлдә
тау итәгенә,
Тизрәк бер чишмә эзләп
киткәнмен янә.

Автобусы китеп барган,
мине көтмәгән.
Бер кеше чыкты алдыма —
кулында китмән.

Китмән тоткач, эшли булыр,
татардыр бу, дим.
«Су бир, үләм,— димен моңа,—
Дим буеннан мин».

Исе китеп карап торды
бу миңа никтер.
Килеп авызымны ачты,
әйтте: «Әй, тик тор!
Әгәр татар икәнсең син,
синең авызда
Ике тел булырга тиеш,
Ә син явызда
сыңар тел, анысы да көтек,
йөрисең, өтек,
Маңгаеңа сыңар мөгез
үскәнне көтеп!»

Хурлыктан хырлап уяндым,—
җитди уйландым.
Ярый әле бу төш кенә,
диеп уйладым.

Инде өндә теге кеше
басты каршыма:
«Авызың ач, икенче тел,— ди,—
куям — карышма!»

Әллә өн бу, әллә төш бу?
Әллә көн бу, әллә төн?
Ачык авыз, дәшми явыз,—
Әллә мин бу, әллә кем?

## *Кешеләр һәм этләр...*

Эт җитәкләп парк буйлап
йөридер кеше.
Парктагы люк астында
балалар өши.

Эт җитәкләп алып барыр
кайларга кадәр?
Карап торам сәерсенеп
байларга мәгәр.

Акчасы күп, баласы юк,—
наркотик сата.
Парктагы люк астында
балалар ята.

Эт бәдрәфе икән хәзер
шәһәр бакчасы.
Эт тизәген себереп ала
кемдер акчасын.

Эткә хезмәт итә икән
тагы да берәү.
Халыктан зур булыйм дисәң,
шуларны күрмә...

Эт җитәкләп парк буйлап
ап-ак яулыктан
Депутат анасы йөри
тиргәп халыкны:
«Эттән дә күп үрчеделәр
хәерчеләр,— ди.—
Этнең итен урлап ашый
хәерсезләр»,— ди.

## *Төен*

*(Россиядә халык санын алудан соң бер уйлану)*

Төелә халык, төелә
Империя көенә.
Империя куштаннары
Шул төенгә сөенә.

Чишелмәслек итеп төйнәп
Чаптырмакчы булалар.
Чапканнарны тагын бер кат
Яптырмакчы булалар.

Үз-үзеннән китмәгәнне
Анда күптән сөймиләр.
Җанга төен төйнәр өчен
Менә ничек сөйлиләр:

«Теле, дине бер булса да,
Булсыннар ике халык.
Буталсыннар, комлы суда
Без — тотучылар балык.

Урап һәм убып алабыз,
Кыеп алабыз җанын.
Төшләренә дә кермәсен
Үзләре булган чагы.

Тарих кабатлана бит ул,
Тагы үз эшен эшләр.
Бер якны кулда тота алсак
Тагын пешәчәк эшләр».

Җан кадәр җанны пешереп
Кем ашарга җыена?
Идел–Урал арасында
Үзең булу тыела...

Юкса Идел белән Урал
Тирән дә биек тә бит.
Милләтебез ошбу җирдә
Борынгы, бөек тә бит...

Ача алса әгәр күзен,
Күреп алачак үзен.
Томаламасаң авызын,
Ярып әйтәчәк сүзен.

Әлегә башта — аяк.
Сыртка сугылган таяк.
Телгә салынган балта,
Аякта — богау,— атла!

Шул халәттә тора бүген
Татар Башкортстанда.
Үзе булып яши алмый,
Әллә язган һуштан да?

Тирмә диләр туган йорты,—
Татар ышанган була.
Гармун тартмый, ул курайга
Өргән, мышнаган була.

Төеләә халык, төеләә
Империя көенә.
Өзгәләнә ялгыз гармун
«Кара урман» көенә.

## *Beləсeң килсə...*

*(Түрəгə)*

Беләсең килсә халыкның
Әгәр ни уйлаганын?
Белмәк булсаң кайда ялган,
Кайда чын уйнаганын? —
Җаны чишелгән мәлләрен
Тилмертмә зинданнарда!
Рәсми рөхсәтләр сорама
Халыкны җыйганнардан.
Табигый дулкын хәлләрен
Сөйләрме буылган су?
Күрсәтмә, фәрман, боерыклар,—
Һәммәсе әйтә: бу! бу!
Беләсең килсә халыкның
Ниләрдән уелганын,
Беләсең килсә җыенның
Ниләрдән җыелганын? —
Искә төшер, син, үзеңнең
Илаhи бала чагың! —
Әнә шул ихласлык белән
Ул яшәр иде тагын...
Дулкын хәлен дулкын гына
Аңларлык хәлгә калдык.
Куллар булса, богауларның
Яңаларын ясадык...
Инде шул хәлләргә төштек:
Яшибез уйсыз гына...
Тик сабыйлары туалар
Аяксыз, кулсыз гына...

## *Үлде... китте... юк...*

Өч төрле теория бар
Бер мәхәббәт хакында:
«Сөю үлде», «Сөю китте» һәм...
«Сөю юк» тагын да.
«Үлде» дигән — үтерүче.
«Китте» дигән — куучы.
«Юк» дигәне — югалтучы
Һәм дүртенче галәмәт бар:
Сөюче — сөелүче.

Сөю булган, бар, булачак! —
Аксиома болары.
Сөюгә тел тидерәләр,
Җитәлмәгәч буйлары.

## *Шул гына бит...*

Син йокымнан мине
ник уяттың?
Мин оныткан идем,—
ник уйлаттың?
Бөреләрне күзләр
ачамыни?
Мәхәббәттән кеше
качамыни?

Син — күзге җил, бары
шул гына бит,
үткәннәрдән кайткан
уй гына бит...
Тылсымланган кебек
ияргәнмен,—
Борылып баксаң,
улым дияргәме?

## *Ялгыз калган күңелгә*

Таң алдыннан бер кош сайрый,
Сайрамый икән, елый.
Сайрар дәртләр бирер ярын
Югалткан, шуны уйлый.
    Уй гынасы таң чыгыдай
    Яфракларга түгелә.
    Җыры — елау, елавы — җыр,
    Ялгыз калган күңелгә.
Ялгыз калган күңелләргә
Таңнар да шәфәкъ, димә.
Төн карасын юа таңнар,—
Кара күлмәгең кимә.
    Таң алдыннан сайрый бер кош,
    Сайрасын гына, тимә.
    Сайрар дәртләр бирер ярым
    Югалттым гына, димә.

## *Аерылышу*

Тәрәзәдән карап торам ялгызым.
Күзләремнән кайнар яшьләр тамызмыйм.
Минем өчен йомшарды да кыш елый,—
Ах, ялгыша: кушылырдыр дип уйлый.

Тәрәзәдән карап торам, дөнья — ак.
Димәк, дөнья туй күлмәген кияр чак.
Таллар инде сыгыла да бөгелә.
Көмеш чыклар күз яшьләре түгел лә...

Тал күңеле көмеш мамыктыр ла,—
Үбәләр дә, әй сүнә кар кызлары...
Шундук эреп юкка чыга алар,
Һич тә аңламассың, әй бу кызларны...

## *Пышылдадың...*

Ике тирәк арасында
асылмалы урындык.
Урындыкка икебез дә
утырдыкмы утырдык.
Әкерен искән җилләрдә дә
пышылдашты тирәкләр:
Сездәй пар тирәкләр кебек
пар килгәннәр сирәкләр.
Ике тирәк арасында
асылмалы ай гына,
Колагыма пышылдадың,
пышылдадың җай гына:
Әкрен искән җилгә түгел,
ышан минем сүземә.
Сөям, дисәң, айны алып
төшеп бирәм үзеңә.
Йөрәклардән йөрәкләргә
салынган икән күпер.
Яфрак-яфрак йөрәкләргә
мәхәббәт утын күчер.

## *Бәхет сине эзләсен...*

*Илгизәгә*

Елый күрмә, авыр диеп, елама!
Башкаларга җиңел диеп, уйлама.
Елый күрмә, шатлыклардан түгелеп.
Һәр кешедә мөлдерәмә күңел бит.
Көлә күрмә, язмышымны җиңдем дип.
Язмышларны җилләр алып җилде, дип.

Эзлә генә, югалтканың табылыр.
Керәм диеп бәхет җиле кагылыр.
Анда кемдер ишек шакый, кем икән?
Әллә бу көн бәхет килер көн микән?
Мәхәббәтне кире какма, кирәк бел!
Мәхәббәтсез яши алмас йөрәк, бел!
Елый күрмә, көлә күрмә, түз лә син —
Син бәхетне, бәхет сине эзләсен!

## *Җыр яз диючегә*

Мәхәббәт турында җыр яз,
Безнең авыл хакында.
Пар тирәкле урамы бар,
Елгасы да якында.

Мәхәббәт хакында җыр яз,
Мәхәббәт чишмә икән.
Мәхәббәттән яра алсаң,
Серләрең чишмә икән.

Мәхәббәт чишмәләре бар,
Туктамый җырлап тора.
Сөю серен ул beләдер,
Чишмә җырыннан сора.

Чишмәләр кебек җырла син,
Серләрең чишелмәсен.
Мәхәббәт — тау, шулкадәр дәү,
Җаныңа ишелмәсен.

## *Сер чишү*

Мин дә килдем сиңа, әй пар тирәк.
Тик шикләнәм серем сөйләргә.
Йөрәгемдә янган ялкынымнан
Әйләнергә мөмкин көлләргә.

Яфрак йөрәкләрең ут алыр да
Коелыр да төшәр каралып.
Шул хәлләрдә, тирәк, минем җаным,
Минем җаным шундый яралы.

Әй пар тирәк, сезнең арада да
Кул биреме генә ара бар.
Безнең тәрәзәләр арасында
Тик кызарып пешә алмалар.

Аның хатыны бар, бар дисәң дә,
Яратмый ул аны, яратмый.
Мин пәрдәмне ябам, тәрәзәмне,
Үз-үземне ябам, каратмыйм.
Аның тарафына, ә күңелне
Ябып куеп булмый, юк инде.
Чакыра да тора, ялвара ук:
Зинһар өчен, зинһар, чык инде.

Бакча якта әгәр ул күренсә,
Борылып карый алсу алмалар.
Күршеңдә, дип, ике алма битле,
Син алмасаң, ала башкалар.

Башкалары аның кирәкми шул.
Алма өзеп әллә атыймммы...
Кышкы бәсләр тәрәзәсен каплый,
Беләм, каршы алмый хатыны.

Тыным белән тартып алыр булып,
Көтеп торам аны мин генә.
Үзем әйталмадым, тирәккәем,
Әгәр килсә, зинһар, син сөйлә.

Икебезнең тәрәз арасында
Ап-ак чәчәк ата алмагач,
Алма пешә, алма өзелеп төшә,
Өзелеп төшә чара калмагач.

Икебезнең йөрәк арасында
Ап-ак чәчәк ата алмагач.
Юлларына өзелеп төшәсең шул
Йөрәгенә керә алмагач.

## *Шулай инде...*

*(Шаян җырлар)*

Авылымның уртасына
Пар тирәк утыртканнар.
Безнең авылдан китсеннәр
Сөяргә онытканнар.

Пар тирәккә ялгызлар да
Килгәләп киткәлиләр.
Утызлары узганнар да
Ярларын көткәлиләр.

Пар тирәкнең ботаклары
Җирләргә тимәс иде.
Кырык яшең җиткән чакта
Кырык яр килмәс инде.

Пар тирәк утыртканнар шул
Авылым уртасына.
Булмаса, сүз кушып кара
Тешсез бер корткасына.

Пар тирәкнең, пар тирәкнең
Пар гына йөрәкләре.
Пар тирәктә яр тапмасаң,
Бетә шул кирәкләрең.

## *Чечнядан хат*

Килгәнсеңдер, бәлки, килгәнсеңдер.
Килмәсемне, бәлки, белгәнсеңдер.
Пар тирәкнең шәрә чыбыгына
Яфракларын җыеп элгәнсеңдер.

Җилләр генә, бәлки, сине жәлләп,
Исеми торгандыр ла, торгандыр.
Төн озынга инде күкрәгендә
Сагышлардан сырган юргандыр.

Пар тирәгем урамнарда калды,
Эзләп йөрдем аны бик озак.
Мәхәббәткә, хәтта гомерләргә
Салына ла икән зар-йозак.

Үлем утын кулга кыскан килеш
Офыкларга бакты күзләрем.
Серләремне тик җилләргә салдым,
Пар тирәккә илт, дип, сүзләрем.

## *Пар тирәк*

*(Җыр)*

Безнең авыл урамында
Үсә икән пар тирәк.
Сөйгән ярын күрер өчен
Шунда килә яшь йөрәк.

К у ш ы м т а:
Әй пар тирәк, пар тирәк,
Йөрәгемә пар кирәк.
Сөйгән ярым ник килмәгән,
Әйтсәң икән, пар тирәк.

Язлар саен, язлар саен
Яфрак яра пар тирәк,
Пар тирәктә очрашмаган,
Серләшмәгән пар сирәк.

К у ш ы м т а:
Әй пар тирәк, пар тирәк,
Йөрәгемә пар кирәк.
Пар тирәктә очрашмаган,
Серләшмәгән пар сирәк.

Көзләр саен, көзләр саен
Яфрак коя пар тирәк.
Язларда да, көзләрдә дә
Гомерлеккә яр кирәк.

К у ш ы м т а:
Әй пар тирәк, пар тирәк,
Туктаусыз яна йөрәк.
Сагышымны яфрак итеп,
Җилгә сип син, пар тирәк.

# *Үткәннәрдә үпмәгәнгә*

Үпкәлисем килә иде,
Үпкәләп назланасым;
Үпкә сүзләремне әйтеп,
Бераз кызгандырасым,
Әз генә җәлләтәсем дә,
Әз генә җан атасым,
Әнә шулай сөюемне
Назланып аңлатасым.

Ул чак янымда булмадың,
Әй көйдем, көйсезләндем.
Назсыз, язсыз гына башым,
Алай да көрсенмәдем.
Килереңне беләи идем
Гомерем көзләрендә.
Үпкә-сагыш чагыладыр
Наз тулы күзләремдә.

Син дә үпкә саклагансың,
Үпкә сүзләр кирәкми, —
Өзеп ташла үткәннәргә
Үпкә тулы йөрәкне...
...Үткәннәрсез, үпкәләрсез
Үтәр микән үпкәләр...
Үткәннәрдә үпмәгәнгә
Бик тирәндә үпкәм бар.
Бар!



## *Еракта йөрәктә*

Мәрхәбә әби хат алган.
...еракта улы.
Күрше кызы укып бирде
хатны бу юлы.
«Дорогая моя мама»,—
дигән үзенә.
Әллә нинди авыр яшьләр
тулды күзенә.

Үскән чакта «Әнкәем!» дип
әйтә иде бит.
Көнен китсә дә, сагынып
кайта иде бит.

Мәрхәбә әби хат алган —
...улы еракта.
Әллә нинди шомлы уйлар
хәзер йөрәктә.

«Әнкәй» дигән гап-гади сүз
җитми шул аңа.
Ят сүзләрдән аның бары
сагышы яна.

Нигә: «Нихәл, әнкәй!» — диеп,
башламый хатын.
Нигә алай төчеләнү,
белмиме затын?!

«Әнкәем» дигән бер сүзгә
һәммәсе сыя.
«Дорогая моя мама» —
җанкаен кыя.

Күрше-күләнгә күптин-күп
сәлам юлламый.
Әллә авылдашларын ул
бер дә уйламый?

«С приветом,—
диеп куйган,—
твой сын Назми».
Күрше кыздан хат яздырды
йөрәге түзми:
«Үз уеңны үз телеңдә
әйтә алмагач...
Әнкәң янына бер көнгә
кайта алмагач,
Ул кайсылай «дорогая»
буладыр инде.
Киткәнеңә егерме ел
туладыр инде...
Син киткән елны утырткан
затлы алмагач
Тәрәзәгә авып төште,
чара калмагач».

Җавап алалмады әби
язган хатына.
Җаны әрнеп китеп барды
Хода катына.



## *Ачыш*

Син дә, бәлки, бүген миңа
Бер җыр чыгаргансыңдыр.
Әлегәчә, белмим инде,
Ничек чыдагансыңдыр?

Җилләре дә бертуктаусыз
Пышылдап тора таңда.
Белсәң икән ниләр барын
Җилләр актарган җанда.

Җил булып җилләр елады,
Кояшны күрдең инде.
Төн караларында түгел,
Гүрләргә кердең инде.

Төн карасы — ни аңа,—
Тарала да тарала.
Аеңны югалта күрмә,—
Айдан аклык ярала.

Ай булып ай чыдамады,—
Кояш артына качты.
Үзеннән дә зур сөюне
Бүген дөньялык ачты.

Әй, дөньялыкка ни аңа,—
Дөньялык фани бит ул.
Мәхәббәт — мәңгелек, дигән
Сәгатьне саный бит ул.

## *Ай китәр ул...*

Йә, эндәшмә миңа телефоннан.
Йә, шакыма минем ишекне.
Сагынсынар бары сине генә,
Саргайсыннар сине ишетми.

Йә, хәерле булсын иртәләр дип,
Теләмә син матур теләк тә.
Сөюеңне читлегенә бикләп,
Саклап кына яшәт йөрәктә.

Бер ялгызың гына чәеңне эч.
Үзең генә пешер ашларың.
Сиңа килеп тезләнмәгән ярлар
Горур йөретсеннәр башларын.

Ә төннәрен тәрәзәңә килеп
Ай караса, чишмә сереңне!
«Төшә күрмә минем янга! —
Сакла,— диген,— менгән үреңне!»

Һәм...ай китәр, әллә синнән генә
Киткән дисең айны шушылай?
Ул курыккан җиргә төшүләрдән,
Соңлап кына килгән һушына.

Хәзер менә һәр тәрәзә саен,
Һәр күңелгә килеп сыгына.
Җир егетен сөйгән мизгелләрен,
Җаны ачык чагын сагына...

Йә, эндәшмә миңа телефоннан,
Йә, шакыма, чишмә сереңне!
Төшә күрмә сөю дарьясына,
Сакла, сакла менгән «үреңне»!

## *Әйләнеп кара әле**

*(Җыр)*

Әллә каян килеп кердең
Кояшлы балачакка.
Җитен толымнарың сибеп,
Йөгердең кайсы якка?

Әйләнеп карамадың,
Әйләнеп карамадың.
Йомшак җитен чәчләреңне
Күрдем җил тараганын.

Толымнарың белән җанга
Юллар салгансың икән.
Шул юллардан яшьлегемә
Кереп калгансың икән.

Әйләнеп кара әле,
Әйләнеп кара әле.
Күңелемдә һаман да син,
Син салган яра әле.

Толымнарың инде хәзер
Җитен түгел, кар икән.
Тагын очрашты карашлар —
Чын мәхәббәт бар икән.

Әйләнеп кара әле,
Әйләнеп кара әле.
Мәхәббәтем шул юл буйлап
Һаман да бара әле...

---

* Чулпан Зиннәтуллина көе.

# *Сөюгә кайтыйк әле!*

Без җырладык
шашып-шашып,
Биедек кочаклашып.
Бүген безгә ниләр булды? —
Ник йөрибез адашып?

Синсез-минсез бу җир шары
Әйләнмәс дигән идек.
Ак бәхетләр генә теләп,
Ак күлмәк кигән идек.

Кышлардан көнләшәм хәзер,—
Ак кар туй күлмәгеме?
Җаннан сөю түгелгәндә
Ак карлар күрмәдеме?

Ак карлар да күреп торды,
Ярсу ташкыннар тойды.
Көнче җилләр шатлыкларны
Саргайтып җиргә койды.

Җил җырлады
шашып-шашып,
Яфраклар кочаклашып,—
Сагыш туе ясадылар.
Без йөрибез адашып.



# IV

*Кыз әйләнде бу батыр яшь тирәли,*
*Җир әйләнгән кебек Кояш тирәли.*

Сәйф Сараи
(1321 еллар тирәсе — 1396)



## *Җанны өткән мизгелләр*

Беләм синең язганыңны
акылдан —
Сиңа кайнар сөю угы
атылган!
Ник дәшәсең, яздыручы
акылдан —
Чакырма, соң! Кочагыңа
атылмам...

* * *

Кош очканда, кеше ялгышканда
кайта асылына.
Үз-үзеннән киткәч,
кош — җәяүгә кала,
кеше — асылына...

* * *

Минем иманыма пычрак
кулын сузгач,
Берәү вәгъдә итте миңа
Оҗмах!..

* * *

Урлашмаска вәгъдә бирде:
«Вәгъдә — иман!» — диеп.
Кулын биреп чыгып китте...
Итегемне киеп.

* * *

Ай-һай, диләр, кире кеше —
Ташы кайнар, пешми эше.
Андыйларның җаны пешә,
Күмер булып җиргә төшә.

* * *

Яна учак, җылыналар.
Якынрак җыелалар.
Аннан таптап сүндерәләр,
Утны шуңа көндерәләр.
Ә мин кеше, учак түгел,
Сынсам, сынам, сүнми күңел.

* * *

Йә яратып кына була.
Була куралмаска.
Болар арасында булмый
Уртак сүз дә, алмаш та.

* * *

Батарга дип әзерләнгән
Ак ай таңга: «Сөям,— диде,—
Ләкин китәм, мин кояшның
Сөюеннән көям»,— диде.

* * *

Рәхәтләнеп ява карлар,—
Күк бәгыреннән өзелсә...—
Туңган күз яше алар.

* * *

Җанда яккан утны күрми,
И бәндә...
Утын эзләп китереп чапты
Имәнгә...

* * *

Очкан чакта уйланырга
Вакыт бик тә, бик тә тар.
Карларны — җилләр...
Кешене
Ашыктыра вакытлар.

* * *

Аңласак та, алдасак та,
Дөнья безне кичерә.
Алдап-йолдап, этеп-төртеп
Мәңгелеккә күчерә.

* * *

Җир астыннан юллар яра чишмә,
Бәреп чыгалмагач,
Гәүдәләрен ташлап оча җаннар,
Чарасы калмагач...

* * *

Башта үз ярымны, аннан
үз җырымны эзләдем.
Үз-үземнән ташып чыгып
качтым, ахры, түзмәдем.
Хәзер инде җирем башка —
...кояш аста.

* * *

Хәлең хәлме, гомерең җәлме? —
Бүген дә ялгыз үтте.
Мине жәлләүче табылды,—
Ай төшеп күздән үпте...

* * *

Уйсыз, моңсыз кешеләр дә
бардыр.
Күңелләре буп-буш
ярдыр...

* * *

Синдә шулкадәрле әйбәт,—
җылы су бар юынырга.
Синдә шулкадәрле авыр —
җылысы юк юанырга...

* * *

Өйгә кереп була да бит
шакып кына.
Җанга керү мөмкин бары
шашып кына.

* * *

Күңел артык очынса,
Күз йомыла,—
көн ояла...

* * *

Төнгә кермәс өчен тарткалашам,—
Төштә сиңа барам.
Таңнар бар да бертөсле башлана,—
Бәйлим тагы ярам.

* * *

Саным гына синнән китте,
саным гына.
Син җаныңда алып киттең
җаным гына.
Җаның юктыр, диләр миңа,
беләләр шул.
Җансыз калган халәтемнән
көләләр шул.

* * *

Язган идем сиңа җыр,
булмады җырлап.
Язылган булып чыкты ул
хисләрне урлап.

Ул җырдагы тирән күлгә
һаман керәсе килә.
«Үзеңнән дә урлашма»,— дип,
тик йөрәк кенә көлә.

* * *

Җил исте —
яфрак төште.
Сап-сары кояш төсле.
Көн үтте —
эңгер төште.
Синең күзләрең төсле.
Елмаеп чыкты
ак ай.
Таң гына җирне аллый.
Бар төсләр мине алдый.
Чын дөнья башка төсле.

* * *

Көткән чакта мәхәббәт,
Җаным алды җәрәхәт.
Ул... мәхәббәт көтмәгән,—
Җаның сөю өтмәгән.

* * *

Дөнья — сагыш.
Дөнья — табыш.
Дөнья — агыш.
Дөнья — тавыш.
Дөнья — шатлык.
Һәм югалту.
Ул торгынлык,
Тик ул тынлык.
Һәм шушылар
Бар да чынлык.
Сиңнән башка
Берсе дә юк,—
Бу да чынлык.

* * *

...белдем мин...

Бәхетсез дип уйладылар,
Елаганымны күреп.
Бәхетле дип көнләштеләр,
Елмайганымны күреп.

Еладым шашып бәхеттән,
Кайгылардан көлдем мин.
Көлүемә кайгыларның
Чыдамасын белдем мин.

* * *

Хисләр әсир итсә
әгәр шагыйрьне,
Хисләр әсир итә алмасалар? —
шагыйрьме?

Хисләр әсир итә калса
шаһ ирне,
Күкләргә
күтәрелерсең...
Һәм... сагынырсың
җирне.



* * *

Күрәсездер, әле кояш бер
ут шары.
Шуңа күрә җир шарының
тугры яры.

Әгәр кояш якын килеп,
җирне кочса,
Ут шары да җир шары да
утка оча.

## *Сорау*

Нинди тәртип бу дөньяда,
нинди сафлык!
Кояш, ае, йолдызлары —
гали шатлык!

Кеше туа! — нинди шатлык!
нинди сафлык!
Кояш, ай вә йолдызларга
йөзе хас тик.

Ник берзаман китә сафлык,
сүнә шатлык?
Бар дөньябыз җәһәннәмгә
була хас тик.

Аңлашылмый яшәү яме
бик күпләргә...
Әллә сирәк багабызмы
без күкләргә?

## *Дөнья чүбе*

Тарталганнар тартып бара
дөнья йөген.
Тарталмаган чәйнәп бара
дөнья чүбен.

Дөнья чүбе һич кимеми,
тик ваклана.
«Эшләдем»,— дип, чәйнәүчеләр
гел аклана.

Тарткан тарта, чәйнәүче–чүп
арта бара.
Инде арба авырайды,—
артка бара.

Тартучысын таптый бара,
таптап бара.
«Туучыдан үлүче күп»,—
дия-дия, чүп
чәйнәп бара...

## *Түрәләр мәсьәләсендә*

Түрәләр түгәрәкләнде,—
Ишекләр катлы-катлы.
Дөньядан китә кешеләр
Керергә ишек тапмый.

* * *

«Татар әдәбияты тарихы» китабының VI томы хакында сөйләшүдән соң.

Һич төзәтеп булмый торган
ялганнар бар.
Чын тарихны ялганнарга
ялгаулар бар.
Шуны күреп торган бәгъзе
ялагайлар
Шома гына чын тарихка
«ялганалар».
Ә чын шагыйрь — тарих күзе,—
шуны күрә!
Хакыйкать ачы булганга
күзгә керә.

## Кирәк иде...

Кайгыга чумган иделәр,
Мин җыр башладым.
Иңнәренә баскан йөкне
Алып ташладым.
Син кирәксең, диеп, мине
Кочып алдылар.
Мин җырлаган җырны шундук
Отып калдылар.
Аларга кайгы таратыр
Җыр кирәк иде.
Ә миңа башымны салыр
Җир кирәк иде.

* * *

Бу ни җанда?
Югалтумы? Табышмы?
Ни дип атыйм
Җанга сарган сагышны?
Сагышлардан башка гына
Җан бармы?
Бер сагышсыз җанга җирдә
Сан бармы?

* * *

...куна калды кара
болыт...

Кичә җилләр болытларны
куалмады.
Җир йөзенә кояшлы көн
туалмады.
Төн күгендә куна калды
кара болыт.
Таң күзендә йомылачак
яра булып.

* * *

...үзен-үзе сүндерә...

Су һәрвакыт юлын белә,
Максатын белми, димә.
Суга каршы йөзим дисәң,
Кайвакыт кирәк көймә.
Ут һәрвакыт эшен белә,
Яндыра да көйдерә.
Янучы бетсә юлында,
Үзен-үзе сүндерә...

* * *

...кош булып кош...

Ут булып ут очып китте,
чыдамады.
Агачларның тамырлары
чыдам әле.
Кош булып кош җәяү йөри,
очалмый шул.
Ах, кеше шуыша, атлый алмый,—
Тере килеш кара җирне
кочалмый шул.

* * *

...язмышлар ярылганда...

— Синең йөздә нинди сырлар?
— Әйтмим, сер бар...
— Синең йөздә пар буразна?
— Әйтмим әле, түз beразга ...
— Синең йөздә ачы сагыш йөзеп бара?
— Син белергә телисеңме?
Җанны кара:
Ул — язмышлар ярылганда
алган яра.

* * *

...белгән килеш...

Бу дөньяга киләсең дә
Елыйсың да көләсең,
Белгән килеш бер әҗәлнең
Көтмәгәндә киләсен.

* * *

...килгәнбез шул...

Кызыгасың кошларга,—
Талпынасың очарга.
Килгәнбез шул дөньяга
Кара җирне кочарга.

* * *

...әгәр сине җиңә алса...

Хакыйкатькә кушылса су
бермә-бер,
Вөҗданың белән киңәшләш
бергә-бер.

Әгәр сине җиңә алса
хакыйкать,
Исбат иттең галимлегең
син кабат.

* * *

...дөньясы калган гаҗәпкә.

Җәйге челлә. Бөтен дөнья әлсерәгән,
хәлсезләнгән.
Баш өстендә генә болыт, шулкадәр дә
гамьсезләнгән.
Юкса түзмәс иде таммый, сулып барган
наз-чәчәккә.
Әйтерсең лә шуңа карап, дөньясы
калган гаҗәпкә.

* * *

...әйт, дөньялык!

Ирек!
Сиңа — җаным фида —
Ә ни файда?

Җаным
Калды җир өстендә.
Ә коллыгым — үз көчендә...

Әйт, дөньялык!
Күрсәт көчең! —
Нинди җан бирергә кирәк
Шул ирекне алыр өчен?

* * *

...үпкәләгән юрган ята.

Шаулама, дисең,
урман ул,
Мин түгел.
Юрганымны ачкан булам,
И күңел...
Үпкәләгән юрган ята
бер читтә.
Җылытасы иде шуны
ничек тә.



## *Давыл көтәм...*

Мин давылга гашыйк идем,—
аңламады.
Үзе белән җир гизәргә
алалмады.
«Син көтеп тор өйдә»,— диеп,
алдалады.
Таулар кочагына барып
ауган тагы.

Их, сез таулар, аңламыйсыз,
аңлыйсызмы?
Мәхәббәттән башка яши
алмыйсызмы?

Давыл сөйгән таулар хәле
минем хәлдә.
Тик Давыллар көтәмен шул
үзем әлдә.

## *Авышу*

Җәй уртасы —
Агачлардан
Сап-сары яфрак тама.
Җәй, бирешмә, әй, бирешмә,
Тик вакыт көзгә таба.
Көзнең чоры —
Агачларда
Ямь-яшел яфрак яна.
Көз, бирешмә, көл, бирешмә!
Тик вакыт кышка таба.

Кыш уртасы —
Агачларда
Ялтырый көмеш бәбкә.
Әй, өшисең, яшерен, дип
Куырылган була әнкә.
Кыш уртасы,
Кыл уртасы —
Шартлама салкын сына.
Кыш бирешмәс иде, ләкин
Язның ярсу сулышыннан
Сыгыла аның сыны.

* * *

...сиздеме җаның...

Җилле көндә урман
шау гынадыр.
Ялгыз җанга түмгәк
тау гынадыр.
Түмгәкләргә һаман
абынасың.
Көндез сүнеп, төнен
кабынасың.
Урманнарда бөҗәк —
бизәк-бизәк.
Җангынаңда синең
нинди бизгәк?
Бидемени җаның,
биздемени?
Җаным сүрелгәнен
сиздемени?

* * *

Дөнья, мине сынадың.
Үзең ничек чыдадың?
Үзең сына яздың бит,—
Бәндәләрең азды бит.

Ә мин һаман сөям бит.
Сөю — Алла, диям бит.
Анысын да алып сына,—
Мин күптән гашыйк сиңа.

## *Кичәге яз*

Көзге яз иде ул кичә
һәм ләйсән иде.
«Җаныма ләйсән булып там!» —
дип әйтсәң иде.
Шул җылы сүз җитмәгәнгә
өшегән дөнья.
Ак кар өстенә ямь-яшел
яфраклар коя.
Яшел булса да
яфраклар, өзелгән инде.
Шашынырлык мизгелләрдә
түзелгән инде.
Көзге яз иде ул кичә,
ә бүген исә,
Күз яшьләрен өзә-өзә
ап-ак җил исә.

## *Сөйгән, сөймәгәннәргә*

Сөйгәннәргә кышкы салкын
дус кына.
Өшемәсләр, ике җанны
куш кына.

Сөймәгәннәр кышның үзен
тарсына,
Хет тере гөл үсеп чыксын
каршына.

## *Йөрәк гөле*

Күзнең соңгы чәчәге мин,
әгәр мин сулсам,
Уйламыйча минем өскә
салкын кар яуса.

Гомернең кышы киләчәк,
ә язлар ерак.
Мин үлемсез, әгәр мине
алса бер йөрәк.

Ах, күпме чәчәкләр җирдә
сула йөрәксез.
Кыш, ашыкма, әллә мин дә
шундый кирәксез?

* * *

Күзге көнгә салма әле
бөтен гаепне.
Күзге көн, җил, ул да түгел,
бер син гаепле.

Яфракларның кыштырдавын
тыңлама инде.
Өзелеп төшкән яфрак өчен
елама инде.

Яфрак кыштырдавын тыңлап
йөримен әле.
Өзелеп төшкән яфрак кеби
Йөрәгем хәле.

## *Ат зары*

Кыргый диеп кыйнамагыз мине,
Кыен диеп җанны кыймагыз.
Хисле диеп, артык көчле диеп,
Артык кызу диеп тыймагыз.

Кыеламын, тыеламын кайчак.
Тукталамын сездәй булудан.
Кыргый булу миңа кыен түгел,
Куркам бары сездәй булудан.

## *Татар ирләренә*

Йомырканы чит ояга
салалар да.
Кәккүк булып
моңланалар...

## *Хыянәтче ир сүзе*

О! Мин сөйдем!
О! Мин ничек сөелдем!
Ул белмәде
бердәнберем түгелен.
Бердәнберем
түгеллеген аңлады,—
Көнгә — кояш,
төнгә — аем калмады.
Сөйгәннәр дә,
бердәнберем
дигәннәр дә,
Хәтта җир дә кочагына
алмады...

## *Түзәрлек түгел хәлем*

Түзәрлек түгел хәлем,—
Моң булып түгеләмен.
Күзләр саен өзелергә
Яфраклар түгел лә мин.
Түзәрлек түгел хәлем,—
Үз-үземә дә җәлмен.
Аккан сулар юлын таба.
Ник ярга түгелмәдем.
Түзәрлекләр түгел, димә,
Кеше син түзәр өчен.
Моңнарга салып сыный шул
Хода бәндәнең көчен.
Түзәрлек түзгән өчен,
Түзгәнгә бирә көчен.
Йөрәккәем кабынмасын,
Чишмә сулары эчим.

## *Якты караңгылык*

Караңгы шундый оятсыз,—
мине коча.
Оятыннан безнең өстән
юрган оча.

Караңгы ул мәрхәмәтле,—
мине аңлый.
Каплар иде таң аткач та,—
кала алмый...

Кояш!
Чыкмый тор...

## *Көзге караш*

Сап-сары яфраклардан
Тора икән тирә ягың.
Көтәсеңме, көләсеңме,—
Яфракларның янган чагы...

Әллә яфрак яңгыры бу?
Әллә яфрак карлар ява?
Күреп торам, өсләреңә
Сап-сары болыт ава.

Ник керден соң бу урманга? —
Ник юлыктың бу буранга?
Яфракларның яралары
Җангынаңа күчә бара...

## *Сүз ишеткәч*

Киткән икән синнән диләр,—
сүз инде.
Ишетүләр авыр, әмма
түз инде.

Көткән икән аны, диләр,
яңа яр.
Ә мин беләм, сине тапкан
яңа зар.

Җанга иңгән җанны ярмый
китәлми.
Җансыз бүтән ярга барып
җитәлми.

Бәргәләнә күкрәгемдә
йөрәгең...
Күз алдымда чайкаладыр
өрәгең.

* * *

Мәхәббәтнең газап икәнлеген
күптән аңладым мин.
Дөньяныкы дөньялыкта булса,
аңлый алмадым мин:
Нишләп сөю, нишләп газап үтми,
мин бит күптән үлдем.
Нишләп һаман йөрәк тибә, дисәм,
йөрәк түгел, белдем:
Сөю белән газап фани түгел,
алар бакый икән.
Бакый дөнья ишегемә килеп
шулар шакый икән.

* * *

Синең хакта уйладым мин
таңгача.
Бер дәрвиштән барып җиттем
хангача.

Иң гаҗәбе — төн үтүгә
өн килде.
Минем сәер халәтемнән
көн көлде.

Тәрәзәмә песнәк килгән,—
җим сорый.
Күгәрченнәргә бер дәрвиш
җим турый.

Синең хакта уйлаганмын,—
төн җиткән.
Аңлашыла: мин узган
соңгы чиктән...

* * *

Яфрак-яфрак җан ямаулы,
Көз ямау сала җиргә —
Җан ямаулы, җир ямаулы —
Ямау салынмый җырга.
Искергән җаның, искергән,
Ямау да тота алмый.
Көзге яфраклар ябынып
Йоклап та китә алмый.
Сине күптән салкын үпкән,
Җаның җыртылып беткән.
Ярый, җырың ертык түгел —
Халкың зарыгып көткән.

* * *

Бик югары үрелмим,
Үрелсәм дә күренмим.
Үзем нәни, сөюем зур,
Сүрелсәң дә сүрелмим.

Бик югары үрелмә,
Мәхәббәттән сүрелмә.
Ишегеңне ачып куй,—
Сөю үтсен түреңә.

Җаныңа үткәр аны,
Ул бит яшәүнең яме.
Ул булмаса, җан бушый,—
Миңа шушы җыр ошый.

* * *

Уйларга ирек бирәсең
ак кәгазь битләрендә.
«Һә» дигәнче җимерәсең
мең катлы бикләрне дә.

Йөрәк чыга читлегеннән,—
атлый, сикерә, оча.
Күктәге бөркет егетен
куып җитә дә коча.

Шулкадәрле биеклектә
бөркет кагылса ялгыш,—
Канатлар коелып төшәр
Һәм... хәл ителер язмыш.

# *Көчлерәк...*

Сагынам,
Яшерә алмыйм,
Юләр йөрәк ярата.
Ни дип әйтергә дә белмим
Шул сөюгә карата.

Яратам,
Исәр йөрәгем
Ярый әле гел биктә.
Хода белеп тота икән
Шул шашкынны читлектә.

Баш тартам,
Шул мәхәббәттән,—
Мин йөрәктән көчлерәк...
Читлегеннән чыгалмаган
Йөрәкне йөрим сөйрәп...



# V

*Егет булсаң, егетлек күргәз илгә,*
*Мәхәббәтлек путасын багла билгә.*

Габдерәхим Утыз Имәни
(1754 — 1834)



## *Шундый уен, шундый кыен...*

Бер-беребезне без яраткан идек,
Яратудан без җан аткан идек.
Ә беркөнне аерылдык та киттек —
Нәкъ шул көннән очрашуны көттек.
Менә шундый уен, җанга шундый кыен.

Ә беркөнне очраштырды дөнья,—
Тау белән тау очрашмас ла, димә.
Ишелеп лә ява төссез карлар.
Ярый әле карлар өелә ала,—
Мондый зарны тота алмый ярлар.
Менә шундый уен, җанга шундый кыен.

Яратсак та, ярлар башка безнең,
Күзләр тота карашларын күзнең.
Бер-беребезгә күптән сүз катмыйбыз,—
Сүз катырга бары җай тапмыйбыз.
Менә шундый уен, җанга шундый кыен.

Ә бер мәлне ачылды да ишек:
Алай була алмый! Ничек! Ничек! —
Бәйләнгән күк язмыш кулына,
Китеп бардың чыгу юлына.
Менә шундый уен, җанга шундый кыен.

Һәм син киттең, тәки китә алдың,
Төссез карлар иде артың, алдың.
Шуннан бирле кабатлыймын:
ничек?
Бу уенга юкмыни соң бер чик?
Ахрысы, бу ахырсыз уен,
Җанга шундый кыен...

## *Ирләр күңеле*

Ирләр күңеле ай-һай
каты була.
Сыгылмыйлар алар
юкка-барга.
Тез чүкмәгән, иелмәгән
башлар
Хөкем ителгәннәр
хәтта дарга.

Ирләр күңеле ай-һай
каты була:
Үлем килә —
ирләр аягүрә.
Ирләр халкын
тезләндерә ала
Фәкать сөю генә.



## *Бер фасылга өч халәт*

### 1.

### Язгы карларга

Һәй, юләр кар,
Кышны эзләп йөрисең лә.
Җиргә төшеп җиткәнче үк
Ялкынында эрисең лә...

Язга гашыйктыр шул син дә,
Бер үбүгә җаның фида.
Канатсызның бер талпынып
Үлүеннән нинди файда?

Һәй, юләр кар, алдандың син,—
Мизгел яши алмадың син.
Гөлгә — җылы, сиңа — салкын
Яшәү икән, аңладың син.

Әмма күккә күтәрелү —
Карга да юк, зарга да юк.
Күгеңне югалтып төшкәч,
Тапталмыйча чара да юк.

Тик барыбер үз күгеңдә
Калгансың син язга кадәр.
Язны үбеп, хыялыңа
Барып җиттең инде хәзер.

Ә мин менә язмышыма
Җигелмәм дә инде барып.
Ташкыннарга ышандым да
Торып калдым ярда арып...

## 2.

### Язгы көз

Язгы көзнең ни икәнен беләм:
Көчсез затлар һәрчак үчле була.
Ачылып кына килгән яфракларга
Язгы көздә зәһәр салкын тула.

Өзәм-өзәм диеп искән җилгә,
Түзәм-түзәм диеп яфрак шаулый.
Табигатьтә яз уртасы юкса,
Көзге җилләр үзенә хокук даулый.

Язгы көзне эзсез китә, димә,—
Сары яфрак тулы агач төбе.
Салкын кышны җиңгән садә
яфрак
Җәй башында инде язмыш чүбе.

Язгы көздән өшеп тора жаным.
Керетмәскә иде жанга көзне.
Учларыма сары яфрак җыям...
Яфракларым!
Терелтәсе иде әле сезне...

Язгы көзнең ни икәнен беләм,—
Җанны кисеп шул мизгелләр
көлә...

## 3.

### Язгы кыш

Безнең урамда кар ява:
Язгы кышы да килде.
Язгы кышның ни икәнен
Садә яфраклар белде.

Ап-ак кар ябышып тора
Ямь-яшел яфракларга.
Табигатьнең бу сынавын
Ничек кенә аңларга?

Чал чәчле сабый шикелле
Аптырап калган сирень:
Гомер итеп мин дә белмим
Бу галәмәтнең серен...

## *Игълан бирдем*

Мин сер салмак булган идем сиңа,
Сер сандыгым тулды — ярыламын.
Язмыш җилкәсендә авыр сандык —
Йөртә-йөртә тәмам арыганмын.

Мин сер салмак булган идем сиңа,
Җаннан арткан җанга гына сыя.
Җан ишегең шакып басып торам —
Керә алмыйм, әллә нәрсә тыя.

Җыр салмакчы идем синең җанга,
Сер салмакчы идем сандыгыңа.
Тәүге аһәңе үк килеп җитте
Авыр түмгәк булып барыр юлга.

Аптырагач, игълан бирмәк булдым,
Бар гәзит һәм журнал битләренә:
«Җанлы кеше кирәк —
коткарыгыз!» —
Басып торам дөнья читләрендә.

Игъланнарны аны укыйлар бит,
Берәү килде — игълан буенча, ди.
Менә килдем, сине коткаручы:
«Мин генәдер, минем уемча»,— ди.

«Машинам бар, ике катлы йортым,
Күпме кирәк кадәр акчасы»,— ди.
«Илле умарталы сыйдырышлы
Бал кортлары тулы бакчасы»,— ди.

«Алтын-көмеш, энҗеләргә туен,
Җылы сулы бассейнда коен.
Асыл тиреләрдән туннар тек тә
Рәхәтләнеп кенә гомер ит»,— ди.

Барысы да бар, әмма тик берсе юк —
Ә җан димен, бармы кеше җаны?
Ул да бар иде, ди, базар килгәч
Бартер белән алдым шушыларны.

Тагы игълан бирү кирәк икән:
Җан сатыла, җаннар бартерга.
Үз-үзеңнән китсәң, кайту мөмкин
Бары сәртир калган фатирга.

Серләремне тагы бикләп куйдым,
Җырларымны яптым җаныма,—
Базарлардан кайчан кайтыр иман,
Кайчан кайтыр кеше җанына?



## *И-и-и-й безнең...*

> И безнең иркәләребез,
> Кадерле тиңнәребез!
>
> *Хәсән Туфан*

Шундый,
шундый сүзкәйләрне
Әй килә ишетәсе.
Кадерле тиңнәребезне
Килә тиңнәр итәсе.

Әй килә ишетәсе лә,
Килә тиңнәр итәсе.
Бүгенге хәлләребездә
Безгә ни хәл итәсе?

Иңебезгә төшкән йөктән
Сыгыла бара билләр.
Мондый йөкне үз иңенә
Алса алыр бер юләр.

Ирләрне иркәлисе бар,
Балаларны карыйсы.
Иртә таңнан кичкә кадәр
Заводларда арыйсы.

Кайткан чакта азык-төлек
Алып кайтырга кирәк.
Ир дисезме? Аның инде
Аек көннәре сирәк.

Аны тизрәк яшерергә
Бала-чага күзеннән,—

Керер урын табалмассың
Аның шакшы сүзеннән.

Сабыйларның күзләрендә,
Карашларында сорау:
Ник безнең эти исерек? —
Җанда шул сорау — борау.

Ярты төн авышкач кына
Урынга барып авам.
Йокысы — төш һәм ансы да
Кадерсез көннән дәвам.

Челтер-челтер итә сәгать
Уянам, булмый торып.
Сәгать угы түгел көннәр,
Кирегә булмый борып.

Җан түгел, җиһан күтәрмәс
Авырлыктагы йөрәк.
Юк, мин инде кеше түгел,—
Әллә нәрсә, бер өрәк.

Балалар сизә күрмәсен,—
Елмаю сыгам җаннан:
Дәрескә соңлый күрмәгез,
Йокларсыз әле аннан.

Иркәләп уяткан булам,
Әйтеп җылы сүзләрне.
Ярый ла йокы аралаш
Күрми алар күзләрне...

«Ул» исерек, йоклап кала,
Косыкка баткан килеш.
Һәм менә син шул хәлләрнең
Һәммәсе белән килеш...

Ә кайтуга ишек ачык,—
Сатылган ансы, монсы.
Бу мәхлуктан ни мәгънә дә
Нинди җавап сорыйсың...

Улларым кайтып кергәнче
Кайларга куйыйм икән?!
«И минем кадерле тиңем,
Минем терәгем, иркәм»...

## *Кая ул...*

Әллә ниләр булды миңа,—
Җыр ага җаннан, ага.
Җанымны яшьлектән кайтып,
Утлы мизгелләр чага.

Урам чаты, бакча арты,—
Ах, үбә, янып үләм.
Итәкләргә чыгын түкте
Койма буенда үлән.

Төн оялды да кызарды,—
Ничек тиз ата таңы.
Ник оялдым, ник бер чынлап
Кочакламадым аны?

Шулкадәр ярату тулы
Җанны тыйдым шул,
тыйдым.
Капканы борын төбендә
Шап итеп ябып куйдым.

Һәм... үзем елап җибәрдем.
Ә ул нишләде икән?
Кагылмый гына янымда
Басып торгач та җиткән...

Кагылма, кулга да тимә! —
Үпкәләп китәм хәзер...
Үпкәләтеп үпкән булсаң,
Ни булыр иде, бәгырь...

Хәзер генә шулай дим дә,
Ул чакта, һай, кая ул!
.................................
Йа Хода...Ул...
Пәрдә артына
качып калдым,—
Үтеп китте бая... ул...

Инде хәзер...
Кая ул...



## *Ялгыз чәй*

Иртәнге чәй болай үтеп китте,—
Эчсәм эчтем, эчсәм эчмәдем.
Таң нурлары алсу, алсу иде
Һәм сап-сары иде хисләрем.

Баш өстемә кояш чыгып басты,—
Әй кыздыра: «Әйдә, чәйлә,— ди,—
Ак самавыр өстәл өсләрендә
Кыз чагыңнан ап-ак җәймә»,— ди.

Шундый чакта кайнар чәй эчүдән
Әйт, кем инде, кем соң баш тарта?
Әмма берни әйтә алмыйм менә
Япа-ялгыз чәйгә карата...

Капма-каршы күзгә-күз карашып,
Чәй эчүләр, beләм, күңелле.
Капма-каршы утырып чәй эчәргә
Кеше эзли, их бу күңелне...

Иртәнге чәй. Ак самавыр кайный.
Ул кайнамый икән, уфтана...
Кайнар чәйгә серләремне салам,
Чәем эчсәм, төптә сер кала.

Эчелмәде тустаганда чәем
Иртәнгесе, төшке, кичкесе.
Чәй эчәргә кеше эзли күңел,—
Серләремне салыр юк кеше.

Кояш белән күзгә-күз карашып,
Чәй эчәргә көн дә утырам.

Тустаганга кинәт тамчы тама,—
Кимегән чәйне яшем тутыра.

Чәй эчәргә, чәй эчәргә генә
Сөйләшергә юк-бар сүз генә
Кеше эзлим, стенадан карый,
Ышанмыйча ике күз генә:

Синме мине куган үз яныңнан?
Минме кума, диеп ялынган?
Тустаганда, юк, суынмый икән,—
Сагышларым өеп салынган...

Иртәнге чәй алсу сагыш иде,
Төшке чәем булды ут кына.
Кичке чәем карадан да кара,—
Чәй эчәргә кеше юк кына.

## *Мин... Без...*

Исәнмесез! —
Шундый изге сүзне
Була икән хәнҗәр итеп кадап.
Мин исән дә, менә, йөрәк кенә
Яраланды, инде тора канап.

Син исәнме?
Үзең исәнме соң?
Бу соравым — кагылмаган кадак.
Менә инде шул хәнҗәрне күпме
Мин җанымда йөретәмен кадап.

Исәнмесез,—
Әйе, сезләр — күпләр.
Шаһит булыгызчы күкләр шуңа!
Хәнҗәр илә ярылды да җаным,
Мәхәббәтем йөрәгемнән шуа...

И синме? Сез?
Әйе, мин идем — без.
Мәхәббәтне зинданнарга салып,
Дөнья ваклыгына абына-абына
Синсез йөрим...
...Безләр булып
йөрим мин кадалып.

## *Китеп баручы яфраклар җыры*

Көз дип тормыйбыз әле без,—
көләбез.
Алтын булып, ялкын булып
киләбез.
Көз дип тормыйбыз әле без,
сөйлибез.
Әле һаман яшәү көен
көйлибез.

Салкын җилләр тагы-тагы
иссәче.
Ә тормышның җиле әче,
гел әче.

Салкын диеп аны юкка
тиргиләр.
Көзге җилнең өшегәнен
белмиләр.

Ул бит безгә җылы эзләп
кагыла.
Болытлар да өшегәннән
агыла.
Без дә җылы эзләп җиргә
төшәбез.
Без үлмибез, җылы җиргә
күчәбез.

Аңламыйбыз: нигә кешеләр
көлми?
Җылы җиргә безнеңчә көлеп
керми?
Һаман саен җирне салкын
гүр, диләр.
Җир куенының кадеркәен
белмиләр.

Көз димибез, без көләбез
киткәндә.
Өзеләлми калсак әгәр, өзегезче
үткәндә.
Өзелә алмый калганнарга,
ах, авыр!
Кышкы салкыннарга калып өшесә
бәгырь...

# *Иң гади гали халәт*

Никадәрле гади теләк —
Әйтәсе килә тик бер сүз.
Никадәр самими теләк,—
Атасы килә тик бер күз.

Никадәрле шашкын теләк,
Чаптар аттай ярсый йөрәк.
Шул карашны тотар өчен,
Бәгырькәем, тик син кирәк.

Никадәрле олы хыял,—
Синең иңгә иңне кую.
Никадәрле татлы мизгел —
Синең сулышыңны тою.

Шулкадәрле хыял җитмәс
Биеклекләр ... түбәнлекләр.
Аңлатырга бу халәтне
Сүздә җитми төгәллекләр.

Шуңа ялгыздыр галәмдә
Ае да, кояшы да.
Керфекләрдә күз яшьләре —
Татлы да ул,
Ачы да.



## *Күңел туңган чакта*

Мин кирәкме сиңа? —
Син кирәкме миңа —
Кирәк булган өчен
Килдем булып чыга.

Үзең бик телисең
Беркем ишетмәвен —
Ә нигә ачтың соң
Җаның ишекләрен?

Күңел эреп акса,
Кузгалачак бар да —
Хәтта котыптагы
Мәңге туңлыклар да.

Күңелем бозларына
Тисә икән җаның.
Тере судан торыр
Дәрьялары аның.

Җанны челпәрәмә
Вату кирәк микән?
Ә миндәге туңлык
Боздан түгел, иркәм.

Нәкъ менә кешенең
Туңган күңелләре
Дөнья туңлыкларын
Ясый түгелме әле?..

Бу җанымның шашып,
Ташып түгелгәне...

## *Өелде...*

Өелде, җанга өелде,
Өелде инде болыт.
Юк, яумады яңгыр булып,
Укмашты тик боз булып.
Кар булып та яумады ул,
Карсыз килде Яңа ел.
Тик боз булып каткач тапты
Җиргә таба яңа юл.
Шык та шык мин тәрәзәләрне
Шакыйм җан бозы белән.
Җылы яңгыр көтә кеше,
Бозга карашын беләм.
Хәерсез дип тирги алар
Афәт китергән бозны.
Җаннар каткан, җиргә яткан,—
Гаепле тагын безме?
Җылы булса, яңа таңда
Чык кына буласы да.
Үз ярларына йөгереп,
Елгалар туласы ла...
Җылы юк. Аяк астында
Җир катыш борчак бозлар.
Өелде җиргә, өелде
Күз яшьтән кипкән тозлар.
Тоз да, су да кушылганнар.
Кеше эчәр су тапмый.
Котылмак булып барсыннан
Җир белән йөзен каплый.
Өелде инде, өелде
Өелде инде кабер...
Ятам, аңлый алмый ятам:
Әллә яшәү, әллә туфрак,
Заманмы шундый авыр?

Өелде...
        иелде инде,
Күтәреп кара башың...
Җилкәмнән җиргә егылгач,
«Уф!» — диде кабер ташым...

## *Тик шул өн...*

Әйтерсең лә
    әллә кайчан
        киткәнмен мин
            илдән.
Ят кешеләр,
    сүзләр,
        күзләр —
            бар дөньясы
                үлгән.
Шулчак телефонга
«Алло» диеп
            дәшкән идем.
«Бу — син, —дидең,
        бик тә якын,
            бик тә якын
Кешем!»
Җавап кайтармадым.
Дөньясында
    япа-ялгызмын мин.
Тик шул өн белән
    яшим,
        бик тә якын,
            бик тә якын,
                бик тә якын,
Кешем!..

# *Ишек*

Ишегемә кемнәр килде икән,
Кемнәр көтте икән ачылыр дип?
Кемнәр көтте икән өметләнеп,
Бәгырькәйләрен лә ачырмын дип?
Мин өйдә юк, мин илдә юк хәтта,
Әйтми озаткандыр мокыт ишек.
Кертмиләр диеп көлгән кебек
Карап торгандыр тик елтыр тишек.
Кемнәр килеп, кемнәр китте икән
Бәгыренә бикләп әйтер серең?
Мин өйдә юк, мин илдә юк хәтта,
Чит җирләрдә җырлар эзләп йөрим.
Кайткан идем, телсез ишек сөйли,
Пыяла күз елтыр тишек елый:
«Шулкадәрле озак йөриләрме?
Ачылмагач, ишек булып булмый.
Ачылмагач, бар да ачулана, —
Ачып куй син, мине бөтенләйгә.
Күңелеңне шулай бикләр булгач,
Күчер дә эл мине бүтән өйгә...»
Кемдер дәшә: «Әллә ачмыйлармы?
Онытканнар, озак йөргәнсеңдер.
Гомерең буе көткән кешең килде —
Әле генә китте, күргәнсеңдер?»
Як-ягыма карыйм, бер кеше юк.
Һаман сөйли икән бикле ишек:
«Күңел ишекләрең бикле калса,
Бер кешенең синдә бер эше юк!»



## *Ул көн кирәкми*

Мин инде сине, бәгърем,
Күптән сөймим бит.
Шушы хакта бар кешегә
Күптән сөйлим бит.

Шунсы сәер: ышанучы
Кеше генә юк.
Җан янудан туктамаса,
Сүнми, диләр, ут.

Мин инде, бәгърем, ул сүзне
Сөйлим күптәннән.
Бүгеннән түгел җавапны
Көтәм үткәннән.

Ул үткәндә безнең сөю,
Сөю бетмәгән.
Гомерләр үтеп китсә дә,
Сөю үтмәгән.

Мин инде, бәгърем, ул сүзне
Әйтмим беркемгә.
«Сине сөям» дигән мәлгә
Кайтсам бер көнгә...

Ни әйтергә белер идем,
Әйтмәс идем, юк.
Тик ул көн миңа кирәкми,—
Анда бит син юк.

## *Безнең көймә*

Җәйнең хәле безнең хәлләр кебек,—
Елап тора әнә түбәбездә.
Без дә шул халәткә киләчәкбез,
Бирешмәскә диеп түзәбез дә.

Җәй — күз йомып ачкан ара гына,
Салкын җилләр тора көз сагында.
Яфракларның барын өзеп алып,
Көзләр он итәчәк кочагында.

Җилгә нәрсә, аның эше — өзү,
Инде болытлардан ак кар өзә.
Җиргә төшеп тапталган карларның
Язмышларын күреп болыт йөзә.
Тулышканчы күктә йөзәбез дә
Авыр булгач, җиргә төшәбез шул.
Без күкләрдә кайчан йөздек икән,
Хәзер шундый түбән — түшәмебез.

Безнең канат кайчан каерылган,—
Акчарлаклар оча, йөзә, йөри —
Адымнарны саный-саный кемдер
Язмышларга йозак сала юри.

Ярга йозакланган көймәләрне
Тарткалый да дулкын бер чак өзә...
Безнең көймә безсез йөзеп китте,
Көзләр җитеп килә, күңел сизә.
Йөреп, йөзеп, очып тотам, димә,—
.........................................
Вакыт-җептән үрелгән ул көймә.
.........................................

# *Вакыт... вакыт...*

Хыялың калмасын
үткәндә.
Исемә килдем үпкәндә...

Бу нинди хәл...
минем хыял
Мин туганчы
җиргә килгән.
Мин йөрисе
сукмаклардан
Басып йөргән,
уйнап көлгән.
Инде килеп
мин дә туган,
Вакыт инде
ул хыялга
Кагылмаслык
койма койган.
Вакыт, вакыт! —
соң әз генә,
Соң әз генә
иел инде,
Бөтенләй үк
алмыйм сине.
Чал чәчеңә
тик кулларым
Тик кулларым
белән генә
тиим инде...



## *Әллә инде...*

Син йоклыйсың,
таң нурлары аз гына да оялмый,
үбә дә үбә сине,
үбә, үбеп туялмый.

Син йоклыйсың,
ай нурлары аз гына да оялмый,
керфек асларыңа кереп,
күз караңа оялый.

Син йоклыйсың,
таң нурлары тоташа карашыңа.
Тагы да ялкын салалар
йөрәгем ярасына.

Син уяндың,
таң җилләре әллә телдән калганмы?
Әллә таратып йөриме
дөньясына ялганны?

Таң җилләре
сөйми, диләр, әллә сөймә, диләрме?
Чәчләремнән сыйпап үтә
алар, мине — юләрне.

Таң җилләре
алдашмаслар, алдамас таң нурлары.
Тыңла, тыңла! Яңгырый бит
безнең йөрәк җырлары.

Син уяндың, әллә сизми,
әллә сизми, дисеңме?
Таң нурлары пышылдыйлар

Гүя минем исемне:
«Нәҗибә, Нәҗибә!» — диләр.
Шулай гомер буйлары...
Гомер ахырына кадәр
көттек инде туйларны...

## *Язмыш сәгате*

Аерылу сәгатьләрен
Сак-Сок уйлап тапкандыр.
Үзе тапкан сәгатенә
Үзе килеп капкандыр.

Мин уйлап тапкан сәгатьнең
Исемнәре — кавышу.
Килеп җитмәсен лә безгә
Сак-Сокларның тавышы.

Сәгатемнән алып чөйдем
Кәккүкне карурманга.
Кыскара гомер, кәккүкләр
Һаман санап торганга.

Кавышу сәгатьләрендә
Пар күгәрченнәр генә.
Ышандым пар күгәрченнәр
Аерылу күрмәсенә.

Ә шулай да аерылдык без,—
Сукты Сак-Сок сәгате.
Язмыш сәгате аяусыз —
Аңламый мәхәббәтне...

# *Киту*

Ышанма! —
Мин дә ышанмыйм:
Сөйгән җан китә алмый.
Үзем китеп барам, синнән
Җан гына китә алмый.

Зыңлап,
Өзелердәй булып,
Җан тартыла, өзелә...
Китеп барам, ләгънәт төшсен
Аякларның эзенә...

Ышанмыйм.
Ышаналмыйча
Китеп барабыз шулай.
Китмәскә мөмкин чакта да
Китми калмыйбыз бугай...

Ә хәзер...
Инде хәзер
Киту башка...
Китми калу мөмкин түгел,
Башны бәрсәң дә ташка...



# *Китәм калыр өчен*

Зинһар өчен, гаеп итмә мине,
Түгелде дә китте күңелем.
Юкса беләм үткән гомерләрне
Кайтарулар мөмкин түгелен.

Кайтмасыннар, үзем кайтам менә,—
Күңел өчен ара бармыни?
Җанга кереп эри алмаган яр
Язлар китерерлек ярмыни?

Зинһар өчен, мине гаеп итмә,—
Яз җилләрен генә тыңлап тор!
Гөрләвекләр юлын урап үтмә,—
Уйларымны алар чыңлатыр.

Җилләр минем уйны урладылар,—
Ташкыннарда минем ташуым.
Бу яз, ахры, минем мәхәббәтнең
Канатланып күккә ашуы.

Зинһар өчен, гаеп итмә мине! —
Мин яратам сине: мин әйтәм.
Мәхәббәт тә аккан сулар кебек,—
Язда калыр өчен мин китәм...



## *Оттырган... оныттырган...*

Ахры...
Син.
Син.
Бары син генә
Мине дивана иттең.
Халәтемне төшендең дә
Син үзең ташлап киттең.

Син.
Син.
Бары тик син
Дөньяны оныттырган.
Кошка канатын, балыкка
Күл генәсен оттырган.

Син.
Син.
Син генә тик
Язгы ярларны ярган.
Адәм заты күтәрәлмәс
Олы сөюгә тарган.

Мин.
Мин.
Бары тик мин генә
Дивана, күлсез балык.
Аңла кошның хәлкәйләрен,
Үзең канатсыз калып.

Мин.
Син.
Ахры, икебез дә
Без язгы ташкын бугай.

Юк, мин син кочасы гөлдер,
Син — күктә сайрар тургай...
Ай...

## *Ташкынлы мизгел*

Сагыш, моң, үкенеч тулы
Күңел нишләсен, ташмый.
Тау елгалары шикелле
Ярларга ташлар ташлый.

Сагышлары — сары ташлар,
Зәңгәрсулары — моңдыр.
Калганнары — үкенечләр,
Әйтеп торалар: соңдыр.

Соңдыр ярларга кайтырга,
Соңдыр таулар яуларга,
Соңдыр каткан күңелләрнең
Таш җырларын аңларга.

Сагыш, моң, үкенеч тулы
Ярлар нишләсен ташмый.
Яр сыйдырмаган ташларны
Ташкын тауларга ташлый.

Ташый җил, кояш астына,
Аяк астына ташлый.
Яңа ташкын җанга бәрә,
Түзәм, җанымны ачмый...

## *Чаралары юк иде*

Чәчәкле яз иде ул чак,
Елгалар таша иде.
Язның садә бөреләре
Күзләрен ача иде.

Карашларың үбеп алды,
Керфекләрең ук иде.
Йөрәгемне сиңа бирми
Калыр чарам юк иде.

Йөрәгем төште ташкынга,—
Йөзеп кереп ал инде.
Язмышларым түгелмәслек
Ярым булып кал инде.

Ташкыннары шаулап узды.
Калды мәхәббәт кенә.
Синең күз карашларыңнан
Алдым җәрәхәт кенә.

Ярларыннан түкте язмыш,
Түгелгәнсең ич син дә.
Күкрәгемдә синең йөрәк,
Минем йөрәгем синдә.

Карашларың өтеп алды,
Керфекләрең ук иде.
Йөрәгемне кайтарырдай
Чараларым юк иде...

## *Көмеш хыял...*

Һавада — кош, суда — балык,
утта — ялкын буласы
килү теләген, әйтегез,
инде кая куясы?

Юк канат, саңаклары да,
ялкыны да яндыра.
Утка, суга, биеклеккә
багам да уйландыра:
очсаң да, җиргә төшәсе,
батсаң, су төбе дә — җир.
Уты, суы, биеклеге —
барсы бергә кирәктер.

Бу — мөгаен, мәхәббәттер,—
бу кадәр көтмәс идем.
Кышкы бураннар, димәгез,—
мин туй күлмәгем кидем...

Туй атларым — җилләр генә.
Көмеш тәңкә — карларым.
Кар бөртекләре каплаган
чәчләремнең чалларын...



## *Кошлар кайтканда*

Ах, бу язгы ямансулау,
Ах, бу язгы ярсулар.
Җанымны чакты да китте
Еракларга карсулар.

Кар сулары хәбәр салып,
Җир ачылды, дигәндер.
Сагыш төяп кошлар кайта,
Кошлар кайта өйгәдер.

Бөреләрне биләвендә
Чак тотып тора тирәк.
Читлеген ташлардай булып,
Ашкынып тибә йөрәк.

Шундый чакта синең китү
Җир качкан кебек яздан.
Канатлар сорап ялварам
Аккош исемле каздан.

Аккош каурыйлары белән
Хатлар язам, озатмыйм.
Ватып керә алмаслар шул
Җаныңдагы йозакны.

Хатлар язам, хатлар алмыйм,—
Үз-үземә кайталмыйм.
Шулкадәрләр дә яратам,
Тик үзенә әйталмыйм.

Ах, бу язгы ямансулау,
Ах, бу язгы ярсулар.
Җанымны чакты да китте
Еракларга карсулар.

## *Кабынып сүнү*

Ә ул кичтә шулкадәрле
Аралар якын иде,
Якын килсәң, кабынырлык
Йөрәкләр ялкын иде...
Тыпырдап торды аяклар,
Йөрәкләр терпелдәде.
Битлек кигән йөзләр генә
Берни дә белдермәде.
Куллар үрелде иңнәргә
Болай биергә генә.
Янәсе шулай бииләр
Инде диергә генә.
Читлек эчендәге йөрәк
Күренмәгәч ятларга,
Беркемне чакыралмады
Үзен үзе якларга.
Әнә шулай бер-береңнән
Күңелләр бизә бит ул!
...Ул кичтә
буран котырды,—
Табигать сизә бит ул.

## *Күңел белән көрәшү*

Төн.
Без икәү —
чит кешеләр.
Сәгать суга
күршедә.
Без — икәү,
ә дивар аша
берәве
берьялгызы
күшегә.

Бер,
ике, өч,
Дүрт, биш, алты —
таң туачак төн арты.
Йокысыз төн,—
мин тордым да
сул аягымнан бастым.

Һәм...
кинәт
чайкалып киттем,—
Баш әйләнә
сөюдән.
Ә кояш
яктырак яна
«Хыял исән!»
диюдән.

Мин
өмет иткән
кайнар наз,—
ул көн калды
читлектә.

Калды йөзләр
ачылмыйча.
Алынмады
битлек тә.

Боз
астында
агып яткан
кайнар чишмә
шикелле
ишетелде,
куеп тордым
күкрәгеңә
битемне.

Үпкәләп
чәчләр
сәленде.
Чәч авыр,—
иде башны.
«Һәрнәрсәнең
үз вакыты!» —
дип вулкан
атты ташны.

Ә син
ник ярсыйсың,
дисең.
Ярсымый,
ни хәл итим?
Синең күкрәгеңә
тигәч,
Көйгән бит
ике битем...

## *Сөйләшми сөйләшү*

Телефоннан саннар җыям,—
Саныйм, саныйм,—
алмыйсың.
Син бит минем халәтемне
әйтмәсәм дә
аңлыйсың.

Юк, тыңлама телефонны,
алма, алма,
кирәкми.
Читлеген ватып чыкмасын,—
тыеп торам
йөрәкне...

Үзе челтери телефон...
алмыйм, алмыйм,—
түзәмен.
Мин бит синең ни әйтәсең
әйтмәсәң дә
сизәмен.

Алам, алмыйм телефонны,
Әйтәм, әйтмим,—
көләсең...
Беләм мин чын мәхәббәтнең
көтмәгәндә
киләсен...



## *Оялам*

Оялам ялгызлыгымнан,
Җанымның өшүеннән.
Үз халәтем үзем аңлап,
Кәефем төшүеннән.

Елмаю ягам йөземә,
Өстән генә кершәндәй.
Салкын тыштан бер мизгелдә
Җылы өйгә кергәндәй.

Оялам, ялварса җаным,
Җылы, мәрхәмәт сорап.
Дөп-дөп тибә йөрәккәем
Барсын яхшыга юрап.

Юраганнар юш килүдән
Сизәм, куркам югыйсә.
Үзем күтәрә алмаслык
Олы мәхәббәт килсә...

Хыялымның зурлыгыннан,
Олы, биеклегеннән.
Калынлыгыннан битемә
Ябылган битлегемнең —
Барысыннан да оялам,
Чөнки түбәннән карыйм.
Канатлы кош килеш җирдә
Җәяү йөрүдән арыйм.

Җир тартуына бирелеп,
Очалмаудан оялам.

Шул мизгелдә кеше телле
Бер кош дәшә оядан:
Көнләшәм биеклегеңә,
Хыялың оча биек.
Ул биеклеккә һичвакыт
Меналмый жанвар-киек.

Кош көнләшер биеклекләр
Әгәр тартмаса күккә.
....................................
Чыгачак бары чүпкә...

* * *

Нигә әле...
    син бүген, төшемә кереп,
        шакыдың ишегемне.
Нәкъ элекке кебек булды:
    кертмимен — кичегелде.
Кулыңдагы чәчәкләрне
        тагы куйдың тоткама.
«Киттем,— дидең,—
            мине уйла,
Мине уйла, йоклама».
Шушы әмердән уяндым,
        сөю килгән таңым ла!
Нәкъ элеккечә ялгызлык
Зыңлап тора тагын да.
Нигә әле төшкә кердең?
Ник шакыдың ишекне?
Йөрәк тырпылдый читлектә,
        беркемне дә ишетми.

## *Очраклы учак янында*

Әй су коенасы килә,
күл таныш түгел, тирән.
Җырда гына җырлана ул:
«Тирән булса да, керәм...»

Әй керәсе килә күлгә,
салкын куырыр төсле.
Өшегәндә җылы учак
тартуы шулай көчле.

Суга, утка да кергән бар,
сак кыланам шуңа да.
Өшегән дә, пешкән дә бар,
баткан хәсрәт-уйга да...

Барыбер дә кабат-кабат
чумасым килә, нишлим?
Чыксын дәрья ярларыннан,—
йөрәк кушканны эшлим!

Бит алмасына тиюгә
иреннәр куырыла...
Кайчандыр йөгәнләнгән ат
ах, тагы туарыла...

....Ә... су коенасы килә...
җылынасы учакта...
Тыелып калынмаган шул
хәзергедәй ул чакта...

# *Җылы караш*

Әйт әле мина җылы сүз,—
өшеде йөрәк.
Бөре ачылсын өчен дә
яз үзе кирәк.

Бер җылы караш бүләк ит,
җанга үтәрлек,
Андый караш буладыр ул
кышны сүтәрлек.

Җылы сүз, җылы караштан
җанга яз килә.
Яз булып бөре очында
яшел наз көлә.

Бәхетеннән ташый карлар,—
язгы ташу бу.
Гомердә — көз, мәхәббәттән
чынлап шашу бу.



## *Ярата...*

Ах, сөям,— дисең,—
чынмы бу?
Шаярту булса,—
нигә?
Бүген дә менә
ышанып,
Мин очып кайттым
өйгә.

Ах, дисең, бу
карашларың.
Шаяртма,
йөрәк бит ул.
Шаяртып кына
яраткан —
Коточкыч
өрәк бит ул.

Чү!
Әле сиңа
ни булды? —
Ышанмыйсың? —
ярата!
Койма аша
күрше кызы
Минем кебек
кар ата...
Ярата...

## *Сары гөлләр*

Хәзер киләм диган булып
Юкка көттердең генә,
Өметләрне чәлпәрәмә
Китердең генә менә.

Сап-сары чәчәк бәйләмен
Елмаеп миңа суздың.
Син белмичә, ә мин исә
Ачуымнан пыр туздым.

Син миңа хыянәт иттең.
Әйе, башкага киттең.
Үзең киттең, гомерең буе
Бер мине генә көттең.

Сары гөлләр ... ул чагында
Миңа уналты иде.
Тәүге мәхәббәтне шулай
Мәңге югалту иде.



## *Буйсынмый*

Миндә минем җаным түгелдер,—
буйсынмый нигә?
Мин биргән боерыклардан
кирегә чигә.

Күңеле дә күкнекедер,—
гел-гел очына.
Чыга алмыйм уйларымның
һич бер очына.

Җан, күңел — кайсы кемнеке? —
минеке түгел.
Ярларыңнан ник туктаусыз
түгел дә түгел?

Күктә — болыт, җирдә елга —
агам да агам.
Инде галәм ярларына
туктаусыз кагам.

Ташкын җаныдыр кешедә,—
җирдән таша бит.
Саны җиргә керә,
җаны күккә аша бит...

## *Көнче кояш*

Син инде йокыга талган,
Йокысызда гамең юк.
Ә миңа синсез дөньяның
Бер тамчы да яме юк.

Син, бәлки, йокламыйсыңдыр,
Талгансың уйга гына.
Минем хактагы уйларны
Җаныңнан кума гына.

Бәлки, син дә минем кебек
Багасыңдыр галәмгә.
Ә мин, юләр, хат язарга
Үреләмен каләмгә.

Йолдызлардан тезеп күңел
Язар идек тик бер сүз...
Кара күккә йолдыз чиккән
Сүзне күрә алса күз...

Йолдызлар шундый еракта,
Ә син йөрәктә — җанда.
Мин ялгызым бу тарафта,
Ә син ялгызың анда...

Синең төшеңдә дә шул ук
Йолдызлы сүзләр микән?
Ә мин беләм, ул сүзләрне
Синең күңелең чиккән.

Кояш көнләште: нур белән
Сөртте йолдызлы күкне.
Җаннан сөртеп алалмады
Язмыш язган бүләкне.

# *Синле фасыл*

Бу салкыннар тәмам өшетте дип,
Көтеп алган идем быел җәйне,—
Җәе килде чөлләләре белән,
Ташлап чыгалмадым никтер өйне.

Бу эсселәр тәмам туйдырды бит,
Инде көтәм көзләр җитүенме?
Туган_җирдән өзелеп өзгәләнеп
Инде көтәм казлар китүенме?

Сыгыла-бөгелә көздә елый таллар,
Ак карларны җылытасы бар дип.
Күз яшьләрен көмеш чәчәк итеп,
Салкын кышны яз итәсе бар дип.

Бу салкыннар тәмам өшетте, дип,
Мин тагы да җәйне көтәрмен шул.
Кая икән синле ел фасылы? —
Көтеп ала алмый китәрмен шул.



* * *

Ул төндә кайда йөргәндер,
Айсыз иде күк.
Күңел әйтте: «Син болай да
Чыдадың бик күп».

Айсыз күңел, караңгы төн,
Ах, мин адаштым,
Шашып кочакладым сине,
Үзем алдаштым.

Күңел тик айны эзләде
сер салыр өчен.
Айсыз төн ярады бары
сер салыр өчен.

Шәрә ай күктән урелеп
минем күлмәкне
Кимәкче булган иде лә,
үзе әләкте.

Айга да, күңелсезгә дә
күлмәк кидермә...
Айны үпкән иреннәргә
ирен тидермә...



# *Телефономания*

Син киттең туган якларга,
Өеңә кайтып киттең.
Син китүгә бу җир мине
Бөтенләй ятим итте.

Айлы, йолдызлы күк иде,
Син киттең — кара болыт.
Җиргә үк төшеп басалар
Үтәлмәс ара булып.

Тәңкә карлар кая киткән? —
Ияртеп киттең мәллә?
Кайт, мин болай яши алмыйм,
Хет бераз гына жәллә.

Көн дә иртән вакытында
Телефон челтерәсен.
Мин телефонны алуга —
Хәерле көн теләсен.

Көн буе сабыр итәрмен,
Төн җитүгә шалтырат.
Әле менә карап торам
Телефонга аптырап.

Син киткәнне беләдер ул,
Каралды йөзе, саны.
Сөйләшә торган хикмәт ич,
Бардыр аның да җаны.

Озак шалтырамый торып,
Төшсә әгәр бәгырьгә...
Эзләп килеп йөрмә мине
Сөйләшергә ... кабергә.

# *Адашканмы әллә...*

Адашканмы әллә бар табигать? —
Һәр фасылдан гүя бер мәл бар.
Октябрен онытып яшел калган
Яфракларны үбә ап-ак кар.

Табигатьнең, бәлки, җәедер бу,—
Тупыл, бәлки, мамык коядыр.
Яз тудырган садә яшеллеккә
Җилләр генә мамык куядыр?

Җир шарының, бәлки, көзедер бу? —
Сары җилләр исә кай якка?
Җир алмакчы булам учларыма,
Сары сагыш тула кочакка...

Планетаның, бәлки, языдыр бу? —
Төш күрәме бу җир, өнме бу? —
Яшел яфрак килеш ак кар кочкан
Чәчләреңне юллыйм, синме бу?



# *Шаярудан узгач...*

Син көтәсең,
Мин дә көтәм.
Башлап дәшмим генә.
Күк күкрәде бүген,
Чатыр-чотыр
...атты яшен генә...

Яңгыр, дисең,
Елап җибәрдең бит,
Күкрәү? —
түгел иде күктә...
Ир елавы ничек булганлыгын
Беләм инде күптән...
Җир алмады
Синең яшьләреңне, —
Күлләвекләр — күзләр...
Тып-тып итеп йөрәк тибеп тора,
Тамчы-тамчы сүзләр...
Син китәсең,
Ә мин көтмим инде.
Күзләр җиргә сеңде.
Күкрәп килгән яшен мәхәббәтем
Янә күккә иңде.



## *Без бәхетле идек...*

Без бәхетле идек ул чакларда,
Зәңгәр томан иде күкләрдә.
Без хыялый идек, исәрләр дә,
Көнләшерлек идек күпләргә.

Зәңгәр күкләр шундый зәңгәр иде.
Тәңкә карлар шундый зур иде.
Тәңкәләрне бер-беренә бәреп,
Искән җилләр бары җыр иде.

Кинәт тәңкә карлар бер-берсенә
Өрелде дә, төште кемнәргә?
Күк болытлар җиргә төште үксеп,
Күз яшьләре булып гөлләргә.

Ул чакларда икебез дә түздек,
Югалтуны гүя күрмәдек.
Ак тәңкәләр йөзгән зәңгәр күктә
Җырлы җилгә генә кермәдек.

Безнең бәхет шундый зур иде...
Безнең бәхет шундый җыр иде...
Ак тәңкәләр инде чыңламый,
Зәңгәр күкләр безне тыңламый...



* * *

Төн карасы тәрәзәмнән
керә дә керә.
Һич туктамый «зимагур» эт
өрә дә өрә.
Җил оныткан тукталышын,
исә дә исә.
Яфракларны кәүсәсеннән
кисә дә кисә.
Кем оныткан кара төндә
кайтырга өйгә? —
Атлый да атлый туктамый
һаман бер көйгә.
«Зимагур» җил, «зимагур» эт,
ул да зимагур...
Талчыккансың, тәрәз ачам,
әйдә, миңа кер!
«Уф»,— диде дә кереп ятты
тәрәз төбемә,
Баш астына яфрак салып,
салкын җил генә,
Җил дә исми, эт тә өрми,
атламый беркем.
Чакырсаң да, җилләр генә
керәчәк беркөн...



# *Хыял гөле*

Хыялыңда миңа кайту
　　　тугызынчы трамвайда.
Югалттың син мине җирдә,
　　　мин бит хәзер яшим айда.
Хыялыңда айга очу
　　　давылларның канатында.
Уйламыйсың менеп җитсәң,
　　　берьялгызың каласың ла.
Хыялыңда кыяның да
　　　түбәсендә үсә чәчкә.
Бәйләнмәгән, ахры, безнең
　　　чәчләр чәчкә.
Хыял белән
　　　　чынлыкларның аермасы
Тик җаннарны бер-берсеннән
　　　аермасын.
Кыя гөлең хыялымның
　　　өстәлендә
Мәңгелеккә тамыр җәя
　　　хисләремдә.



## *Ялындырыр өчен генә*

Мин сине тапкан булганмын,
Тапкан булганмын икән.
Җан гынамны мәхәббәткә
Яккан булганмын икән.

Тапканымны аңламадым,
Аңлый да алмаганмын.
Хисләремнең хисләреңә
Мәңгегә ялганганын.

Җанымның яртысы, диеп,
Җанымны ачкан идем,
Ялындырыр өчен генә
Шаярып качкан идем...

Күңел тәрәзләрең сүнде,
Кабат кабыныр микән?
Җан гынаемның яртысы
Кабат табылыр микән?

Кояш нурын өзеп булмый,
Күңелләрне ябып та...
Чын мәхәббәт кире кайтмый,
Башка ярлар табып та...

## *Әйтсәң әгәр...*

### 1.

Әйтсәң әгәр, сагынмыйм, дип,
ялгыз чакта сыгынмыйм, дип,—
хак түгел.
Фани дөнья язга узган, күрәмсең,
мәхәббәттән башка яшәр
чак түгел.

Күз төбендә әллә талның бәбкәсе
көмеш чыктай түгелеп китә,
шул — күңел.
Чәчләремнән сыйпап үткән җил-күңел,
мәхәббәттән яшьләр түккән
мин түгел...

### 2.

Көмеш чыклы таллар башын
кемгә шәлкем гөлләр итеп
кырыккансың?
Әгәр әйтсәң, инде сине сөймим, диеп,
әгәр әйтсәң, юк мәхәббәт,
кырыктан соң...

Көмеш яшьле чәчәкләрең
өстәлемдә.
Миңа инде күптән илле, башка бер сүз
өстәмим дә...
Көмеш яшьле чәчәкләрең —
өстәлемдә...

## *Булмый*

Без барыбер
Аерылмабыз, диден.
Очраштырыр дөнья —
Тар бит ул.
Өермәләр сине
алып китте —
Чын мәхәббәт җирдә
бар бит ул.

Каерылсак та
Кушылырбыз, диден.
Очар өчен канат
пар бит ул.
Ташкыннары сине
алып китте.
Елгаларның яры
бар бит ул.

Аерылсак та,
каерылсак та, диден
Кабат кайтачакбыз
үз-үзебезгә.
Әмма ул чак
шундый авыр булыр
Бер-беребезнең карау
күзебезгә.

Ә дөнья тар,
ә сөю бар.
Үз-үзеңнән
качып булмый!
Һәм күзләрне
ачып булмый.

## *Ярый ла без каеннар түгел...*

Тәбрик сүзе юллагансың
Ни икәнен аңламый.
Җан чаң суга —
мин ишетмим —
Бердәнбер җан алдамый.

Күзләр күрмәгән булалар,
Ишетми колакларым...
Хәтер бөтенләй саеккан
Уйлап дөнья юк-барын...

Тик язгы сут кәүсә буйлап
Барыбер күтәрелә.
Чукрак булсаң да кайтасың,
Кайтасың үткәнеңә.

Кайтасың да шаккатасың
Гомернең үткәненә...
Агачларның һәр көз саен
Яфраклар түккәненә...

Уфтансаң да гөнаһ кебек,—
Агачлар нинди бәйдә!
Ярый без каеннар түгел,
Кеше булганбыз әлдә
Яшибез шушы хәлдә...



## БИОГРАФИК БЕЛЕШМӘ

Нәҗибә Әхмәтнур вә Нурикамал кызы Сафина 1949 елның 2 мартында Башкортстанның Яңавыл районы Кисәк-Каен авылында туган. Сигезьеллык белемне туган авылында, ә урта белемне Карман авыл мәктәбендә ала. Мәктәп елларында ул дружина советы рәисе, комсомол оешмасы секретаре эшләрен алып бара.

1972 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, Татарстанның Кама Тамагы районындагы Балтач авылына татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп билгеләнә һәм шул ук елда Чистай шәһәренең икенче мәктәбенә рус теле һәм әдәбияты укытучысы итеп күчерелә. Чистай педагогия училищесында татар теле һәм әдәбияты, балалар әдәбияты, сәнгатьле уку дәресләре алып бара, рус мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Шул елларда Чистай шәһәр газетасында үзенең әдәби әсәрләрен, лирик парчаларын бастыра. Әмма туган якларында татар теленә, әдәбиятка булган хәстәрле мөнәсәбәте аны Башкортстанга әйди. Ул 1975 елда Башкортстанның Краснокама районына кайтып, район газетасы редакциясендә тәрҗемәче, Яңавыл районы Прогресс урта мәктәбендә директор урынбасары, Чистай районының Дүртөйле мәктәбенә кайтып директор урынбасары булып эшли.

1979 — 1984 елларда кабат Краснокама район газетасы редакциясендә корреспондент, бүлек мөдире, радиотапшырулар редакторы булып тора. Шул елларда

район һәм Нефтекама шәһәр иҗат көчләрен берләштергән «Акчарлак» әдәби берләшмәсе, аннары тагы да киңрәк «Инеш» иҗат берләшмәләренә нигез сала. Туган районы Яңавылда «Заман» иҗат берләшмәсен булдыру өчен күп көч куя, аның утырышларында актив катнаша. Район газетасы битләрендә даими шигырьләрен чыгарып бара. Башкортстан радио-телевидениесендә чыгышлар ясый. Аның шигырьләре «Кызыл таң», «Совет Башкортстаны» газеталары, «Башкортстан кызы» журналында дөнья күрә, «Яшь көчләр» (Уфа), «Кызлар җыры» (Казан) җыентыкларына кертелә. Шул елларда Краснокама район газетасының татар телендә чыга башлавында аның да өлеше зур. Шуннан соң 1990 елга кадәр шәһәрнең «Китап сөючеләр» җәмгыятен җитәкли. Ниһаять, 1990 елда үзе канат чыгарган шәһәре Казанга кайтып, яңа чыга башлаган «Шәһри Казан» газетасында эшли башлый. Яңа газетаны аякка бастыру танылган журналистлар, тәҗрибәле матбугатчылар белән алар җилкәсенә төшә.

Шагыйрә Нәҗибә Сәфинаның киң җәмәгатьчелеккә танылуы әнә шул көннәрдә башлана. Аның ялкынлы публицистикасы, туры телле мәкаләләре, рухиятле шигырьләре, мөстәкыйльлек өмет иткән Татарстан халкының күңеленә бик тә хуш килә. Әлбәттә, ул аңа кадәр дә язмый тормаган, чөнки озак еллар рус телендә, татар телендә булган матбугатта аның исеме гел күзгә ташланып килә иде. Бу очракта шунысын да искәртеп китәргә кирәктер. Ул атаклы Ибраһим Нуруллин университетка җыйган 476 нчы группадан. Үзенең остазы хакындагы «Казан утлары» журналында басылып чыккан истәлекләрендә шагыйрә: «...мин университетта укыганда Хатыйп ага Госман аша бәйдәге хисләремә очыш алсам, Ибраһим ага Нуруллин аша бикләнгән, тыелган фикерләремә бәйсезлек яуладым»,— дип язды. Ул группага кергән исемнәрне генә дә атап китү күп нәрсә турында сөйләргә тиеш: Альберт Сафин, Рашат Низами, Зиннур

Мансур, Җәүдәт Дәрзаман, Рәшит Бәшәр, Раушания Низамова — язучылар, Әнвәр Хәйри — галим, Риман Гыйлемханов — журналист...

Озак еллар буе Татарстаннан, татар матбугатыннан аерылып торган Нәҗибә Сафина ун ел эчендә Татарстан язучылар берлеге әгъзасы гына булып калмады, өч ел дәвамында аның идарә әгъзасы булып та торды. Чыккан китаплары да дистәгә дә җитми сыман: «Таң кошы» (1998), «Әгәр дә уйлаганда...» (2002), «Кош теле» (1996) исемле китаплар чыгарды. Рәссам Марат Сәхибгәрәев белән нәшер ителгән «Мәче фәлсәфәсе», «Аккош күле» китаплары күзгә дә күренми таралып бетте дисәк тә була.

Ул 1992 — 1995 елларда «Сөембикә» журналында сәясәт бүлеге редакторы булып эшли.

Шагыйрә 1997 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Публицистик язмалары һәм проза әсәрләре, шигырьләре өчен диплом, бүләкләргә лаек булды.

## ЭЧТӘЛЕК

Вакыт чикләреннән узачак. *Ә.Гадел* .................... 5

I

Кеше — шигырь .................... 8
Аерылмасны каермагыз! .................... 10
Белү кирәк... .................... 12
Хәлем шундый... .................... 13
Әй, дөнья! .................... 14
Арала! .................... 15
Урман шаулый .................... 16
Мин яшь чакта... .................... 17
Бу — ир, бу — ил... .................... 18
Әй, туган тел .................... 19
Идел, Иделкәй, сагай! .................... 20
Туган телемдә .................... 21
Туган тел — намаз .................... 23
Идел — ил уе .................... 24
Сыгылу .................... 25
Мин дәшмәдем... .................... 26
Йөрәк кысканда .................... 27
Кеше һәм кош .................... 29
Таш хәтере .................... 30
Алай дисәң... .................... 31
«Әй тын иде...» .................... 33
Табигать тә әгәр алдаса... .................... 34
Бүген инде утыз бере .................... 35
Яз булгач... .................... 37
Ялгыз үксү .................... 38
Үз иркем — ирексезлек .................... 40

Йөрәкне йөгәнләү ........................................ 41
Давыл биеклегеннән ........................................ 42
«Кояшым кебек түгәрәк иде сагышым...» .............. 43
Гыйсъян тынлык ........................................ 43
Эзләп барам ........................................ 45
Елау җыры ........................................ 47
Яратам ........................................ 48

## II

Татар җаны ........................................ 50
Булуы кыйммәт ........................................ 51
Кызлар гимназиясенә гимн ........................................ 51
Үз ягына бора ........................................ 52
Уянгач, аңларсыз ........................................ 53
Язмышыңа үзең Алла бул! ........................................ 54
Акылыбызга килик! ........................................ 57
Мәйданнарда ачыла җан ........................................ 59
Татар тукталышы ........................................ 61
Тукайга дәшү ........................................ 63
Рәхмәт, якташ! ........................................ 64
Тукай кабат туар... ........................................ 66
Искә алу көнендә уйлану ........................................ 68
И-и, Тукайҗан... ........................................ 69
Егылмасын, югалмасын дисәң... ........................................ 72
Ә күк эзли ........................................ 73
Ә чынлыкта... ........................................ 74
Фикерлене күтәрә алсак... ........................................ 75

## III

Әй бу күтәрелүләр... ........................................ 78
Җан халәте ........................................ 79
Фанилык кына җаннарга!.. ........................................ 80
Бер биедем туйганчы ........................................ 82
Булмаса да «була» — ул... ........................................ 83
Ы-ы-ы... дөнья көйсез ........................................ 84
Туган көндә «үлү» ........................................ 85
Дөньясы көлеп тора ........................................ 86
Тәүбә... тәүбә... ........................................ 87
Ә без һаман таш җыябыз ........................................ 88

Тама әле... ........................................... 89
Сату ........................................... 91
Ничек туктатасың? ........................................... 91
Мәче белән шагыйрь ........................................... 92
Тәртип... ........................................... 93
«Дәүләтчә» уйлау ........................................... 94
Куышсыз куян... ........................................... 95
Мәсьәлә ........................................... 96
Әллә төш, әллә өн... ........................................... 96
Кешеләр һәм этләр... ........................................... 98
Төен ........................................... 99
Беләсең килсә... ........................................... 101
Үлде... китте... юк... ........................................... 102
Шул гына бит... ........................................... 102
Ялгыз калган күңелгә ........................................... 103
Аерылышу ........................................... 103
Пышылдадың... ........................................... 104
Бәхет сине эзләсен... ........................................... 104
Җыр яз диючегә ........................................... 105
Сер чишү ........................................... 106
Шулай инде... ........................................... 107
Чечнядан хат ........................................... 108
Пар тирәк ........................................... 109
Үткәннәрдә үпмәгәнгә ........................................... 110
Еракта йөрәктә ........................................... 111
Ачыш ........................................... 113
Ай китәр ул... ........................................... 114
Әйләнеп кара әле ........................................... 115
Сөюгә кайтыйк әле ........................................... 116

## IV

Җанны өткән мизгелләр ........................................... 118
«Беләм синең язганыңны...» ........................................... 118
«Кош очканда...» ........................................... 118
«Минем иманыма пычрак...» ........................................... 118
«Урлашмаска вәгъдә бирде...» ........................................... 119
«Ай-һай, диләр, кире кеше...» ........................................... 119
«Яна учак, җылыналар...» ........................................... 119
«Йә яратып кына була...» ........................................... 119
«Батарга дип әзерләнгән...» ........................................... 119

«Рәхәтләнеп ява карлар...» ........................ 120
Җанда яккан утны күрми ........................ 120
«Очкан чакта уйланырга...» ........................ 120
«Аңласак та, алдасак та...» ........................ 120
«Җир астыннан юллар яра чишмә...» ........................ 120
«Башта үз ярымны, аннан...» ........................ 121
«Хәлең хәлме, гомерең җәлме...» ........................ 121
«Уйсыз, моңсыз кешеләр дә...» ........................ 121
«Синдә шулкадәрле әйбәт...» ........................ 121
«Өйгә кереп була да бит...» ........................ 121
«Күңел артык очынса...» ........................ 122
«Төнгә кермәс өчен тарткалашам...» ........................ 122
«Саным гына синнән китте...» ........................ 122
«Язган идем сиңа җыр...» ........................ 122
«Көткән чакта мәхәббәт...» ........................ 123
«Җил исте — яфрак төште...» ........................ 123
«Дөнья сагыш...» ........................ 123
«Бәхетсез дип уйладылар...» ........................ 124
«Хисләр әсир итсә...» ........................ 124
«Күрәсездер, әле кояш бер...» ........................ 125
Сорау ........................ 125
Дөнья чүбе ........................ 126
Түрәләр мәсьләсендә ........................ 126
«Һич төзәтеп булмый торган...» ........................ 127
Кирәк иде... ........................ 127
«Бу ни җанда...» ........................ 128
Кичә кояш болытларны ........................ 128
«Су һәрвакыт юлын белә...» ........................ 128
«Ут булып ут очып китте...» ........................ 128
«Синең йөздә нинди сырлар...» ........................ 129
«Бу дөньяга киләсең дә...» ........................ 129
«Кызыгасың кошларга...» ........................ 130
«Хакыйкатькә кушылса су...» ........................ 130
«Җәйге челлә...» ........................ 130
«Ирек!..» ........................ 131
«Шаулама, дисең...» ........................ 131
Давыл көтәм... ........................ 132
Авышу ........................ 132
«Җилле көндә урман...» ........................ 133
«Дөнья, мине сынадың...» ........................ 134

Кичәге яз ........................................ 134
Сөйгән, сөймәгәннәргә ........................................ 135
Йөрәк гөле ........................................ 135
«Көзге көнгә салма әле...» ........................................ 136
Ат зары ........................................ 136
Татар ирләренә ........................................ 136
Хыянәтче ир сүзе ........................................ 137
Түзәрлек түгел хәлем ........................................ 137
Якты караңгылык ........................................ 138
Көзге караш ........................................ 138
Сүз ишеткәч ........................................ 139
«Мәхәббәтнең газап икәнлеген...» ........................................ 139
«Синең хакта уйладым мин...» ........................................ 140
«Яфрак-яфрак җан ямаулы...» ........................................ 140
«Бик югары үрелмим...» ........................................ 141
«Уйларга ирек бирәсең...» ........................................ 141
Көчлерәк... ........................................ 142

## V

Шундый уен, шундый кыен... ........................................ 144
Ирләр күңеле ........................................ 145
Бер фасылга өч халәт ........................................ 146
Игълан бирдем ........................................ 148
И-и-и-й безнең... ........................................ 150
Кая ул... ........................................ 152
Ялгыз чәй ........................................ 154
Мин... без... ........................................ 155
Китеп баручы яфраклар җыры ........................................ 156
Иң гади гали халәт ........................................ 158
Күңел туңган чакта ........................................ 159
Өелде... ........................................ 160
Тик шул өн... ........................................ 161
Ишек ........................................ 162
Ул көн кирәкми ........................................ 163
Безнең көймә ........................................ 164
Вакыт... вакыт... ........................................ 165
Әллә инде... ........................................ 166
Язмыш сәгате ........................................ 167
Киту ........................................ 168
Китәм калыр өчен ........................................ 169

Оттырган... оныттырган... ........................ 170
Ташкынлы мизгел ........................ 171
Чаралары юк иде ........................ 172
Көмеш хыял... ........................ 173
Кошлар кайтканда ........................ 174
Кабынып сүнү ........................ 175
Күңел белән көрәшү ........................ 176
Сөйләшми сөйләшү ........................ 178
«Оялам...» ........................ 179
Нигә әле ........................ 180
Очраклы учак янында ........................ 181
Җылы караш ........................ 182
Ярата... ........................ 183
Сары гөлләр ........................ 184
Буйсынмый ........................ 185
Көнче кояш ........................ 186
Синле фасыл ........................ 187
«Ул төндә кайда йөргәндер...» ........................ 188
Телефономания ........................ 189
Адашканмы әллә... ........................ 190
Шаярудан узгач... ........................ 191
Без бәхетле идек... ........................ 192
«Төн карасы тәрәзәмнән...» ........................ 193
Хыял гөле ........................ 194
Ялындырыр өчен генә ........................ 195
Әйтсәң әгәр... ........................ 196
Булмый ........................ 197
Ярый ла без каеннар түгел... ........................ 198

Биографик белешмә ........................ 199

Литературно-художественное издание

*Сафина Назиба Ахматнуровна*

ПРОЗА ЖИЗНИ

Стихи

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *М.А.Җиһаншина*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *М.Ш.Хәйруллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 23.01.2004.
Форматы 70×90 1/32. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы
7,61 + форз. 0,15.
Шартлы буяу-оттиск 8,49. Нәшер-хисап табагы
7,66 + форз. 0,26. Тиражы 2000 экз. Заказ Э-16.

Татарстан китап нәшрияты.
420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство.
420111. Казань, ул. Баумана, 19.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.